«76 нчы «Җилкәй» катнаш балалар бакчасы»
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

«Раслана»
Педагогик киңәшмә белән
Беркетмә 31.08.2022 № 1

«Кертелә»
Боерык белән 31.08.2022 № 210
Мөдир ________ Т.В.Мартьянова

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**
по реализации основной общеобразовательной программы
дошкольного образовательного учреждения
на 2022-2023 учебный год
подготовительная группа № 1

**УКЫТУ-ЭШ ПРОГРАММАСЫ**
2022-2023 нче уку елына мәктәпкәчә белем бирү
учреждениясенең төп бердәм укыту программасын тормышка ашыру
( 1 нче мәктәпкә әзерлек төркеме)

Тәрбиячеләр: Билданова Гүзәл Фанисовна
беренче квалификацион категория
Загирова Гөлчәчәк Гаязовна

Яр Чаллы шәһәре

# Эчтәлек


| № | Бүлекләр исемлеге | бит |
|---|---|---|
| **I.** | **Максат өлеше** | |
| **1.1** | **Аңлатма язуы** | 3 |
| 1.2 | Эш программасының максаты һәм бурычлары | 3-4 |
| 1.3 | Программаны формалаштыру принциплары һәм юллары | 4 |
| 1.4 | Эш программасының күрсәткече | 4-5 |
| 1.5 | Ел ахырына үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр | 5-8 |
| | | |
| **II.** | **Эчтәлек өлеше.** | |
| **2.1** | **Тәрбия һәм белем бирү процессының эчтәлеге** | 8-9 |
| **2.2** | **Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге (мәктәпкә әзерлек төркемендә белем бирү өлкәләренең төп максатлары һәм бурычлары)** | 9-44 |
| 2.2.1 | Физик үсеш белем бирү өлкәсе | 9-12 |
| 2.2.2 | Социаль-аралашу белем бирү өлкәсе | 12-16 |
| 2.2.3 | Танып белү белем бирү өлкәсе | 16-21 |
| 2.2.4 | Сөйләм үстерү белем бирү өлкәсе | 21-27 |
| 2.2.5 | Нәфис-нәфасәти үсеш белем бирү өлкәсе | 27-44 |
| 2.3. | **Якынча комплекслы - тематик план** | 45-51 |
| 2.4. | **Ата – аналар белән үз ара бәйләнешле эш** | 51-52 |
| 2.4.1 | Ата-аналар белән үзара бәйләнеш принциплары. | 52 |
| 2.4.2 | Ата-аналар белән үзара бәйләнеш формалары. | 52-53 |
| 2.4.3 | Ата-аналар белән эш төрләренең якынча перспектив планы | 54-55 |
| III. | **Оештыру өлеше.** | |
| 3.1 | Материаль – техник яктан тәэмин итү | 56 |
| 3.2. | Программалы – методик яктан тәэмин итү | 56-57 |
| 3.3. | Җиһазлау | 57 |
| 3.4 | Предметлы - тирәлек мохитны үстерү | 58-59 |
| 3.5 | Мәктәпкә әзерлек төркеменең якынча көн тәртибе | 60-61 |
| 3.6 | Белем бирү эшчәнлегенең челтәре | 61-62 |
| 3.7 | Бәйрәмнәр һәм күңел ачуларны тематик планлаштыру. | 62-63 |
| IV. | Өстәмә бүлек (кыскача презентация) | 63-64 |
| | **Әдәбият** | 65-66 |
| | **Кушымта** | 67-81 |

## I. Максат өлеше

### 1.1 Аңлатма язуы

Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең «76 нчы «Җилкәй» катнаш төрдәге балалар бакчасы»ның 1нче мәктәпкә әзерлек төркемендә эшләүче педагогның эш программасы мәктәпкәчә белем бирү ФДББС« Об утверждении федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования» (Приказ Министерства образования и науки Российской Федерации № 1155 от 17 октября 2013 года), МОиН РФсенең 31 июль 2020 г. N 373 «Об утверждении порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам - образовательным программам дошкольного образования» приказы; СП 2.4.3648-20 "Балалар һәм яшьләрне тәрбияләү, укыту, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына карата санитар-эпидемиологик таләпләр" ; СанПиН 1.2.3685-21 "Кеше өчен яшәү тирәлеге факторларының иминлеген һәм (яки) зыянсызлыгын тәэмин итүгә гигиена нормативлары һәм таләпләр"; СанПиН 2.3/2.4.3590-20 "Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр"; 29.12.2012 № 273-ФЗ «Об образовании в РФ» Федераль канунына, МБМББУ сенең локаль актларына нигезләнеп төзелде. Программа 76 нчы санлы МБМББУсенең төп белем бирү программасына яраклаштырылган, 6-7 яшьлек балаларның төрле өлкәдәге үсешен, аларның шәхси, психологик һәм физик үзенчәлекләрен, ФДББС буенча үсеш юнәлешләрендә ( социаль – аралашу үсеше,танып – белү үсеше, сөйләм үсеше , эстетик – сәнгать үсеше, физик үсеш) үсешен тәэмин итә. Физик үсеш балалар бакчасының өстенлекле юнәлеш эшчәнлегендә- балаларның терәк-хәрәкәттә булган кимчелекләрен квалификацияле төзәтмәләр кертү юнәлешендә алып барыла.

### 1.1 Эш программасының максаты һәм бурычлары:

• Балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып мәктәпкәчә яшьтәге балаларны физик, интеллектуаль, шәхси сыйфатларын үстерү.Балаларның аң һәм физик үсешенең табигый процессына уен, аралашу, танып-белү, хезмәт, хәрәкәт, матур әдәбият уку, музыка- иҗат, ясау эшчәнлеге.

Белем өлкәләрен үзләштергәндә психологик һәм педагогик яктан ярдәм итү.

Режим моментларында, ирекле белем бирү , мөстәкыйль, ата-аналар белән эш вакытында зурлар-кечкенәләр бердәм (партнерлык) эшчәнлеген оештыру

Программа куйган максатларга ирешүдә түбәндәгеләр беренче әһәмияткә ия:

- балаларны аралашучан, игелекле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып, төркемнәрдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру;
- балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен киң куллану; укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны интегральләштерү;
- тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;
- балаларның мөмкин булганча төрле эшчәнлекләрен файдалану; белем бирү процессын нәтиҗәлерәк итү максатында аларны берләштерү (интегральләштерү);
- мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү оешмалары һәм гаилә шартларында бала тәрбиясенә якын килүгә юнәлеш бирү;
- гаиләнең балалар бакчасы төркемнәре һәм, гомумән, мәктәпкәчә оешма тормышында катнашуын тәэмин итү;
- балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балага кирәгеннән артык акыл һәм физик эш йөкләмәү максатыннан дәвамчанлыкны саклау;
- региональ якын килүне гамәлгә ашыру.

**Эш программасының төп фикере** - укыту, тәрбияләү, сәламәтлеген саклау белән бергә баланың шәхесен үстерү.

## 1.3 Программаны формалаштыру принциплары һәм юллары

Программада баланы туганнан алып мәктәпкәчә тәрбияләүнең һәм аңа белем бирүнең барлык төп эчтәлек юнәлешләре комплекслы күрсәтелә.
Программа мәдәни ярашканлык принцибына корылган. Әлеге принципны гамәлгә ашыру белем бирүдә милли кыйммәтләрне һәм традицияләрне исәпкә алуны тәэмин итә, рухи-әхлакый һәм эмоциональ тәрбия бирүдәге җитешсезлекләрдән арынырга булыша. Белем бирү баланы кешелек мәдәниятенең төп компонентларына (белем, әхлак, сәнгать, хезмәт) якынайту процессы буларак карала.
Программалы белем бирү бурычларын өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларның мөстәкыйль эшчәнлегендә хәл итүне турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, мәктәпкәчә белем бирүнең үзенчәлегенә туры китереп, режим моментларын уздырган вакытта да күздә тота.

## 1.4 Эш программасының күрсәткече:

*Белем өлкәләрен интеграцияләү нигезендә тулы педагогик процессны төзү;
*Балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып төп юнәлешләр – физик, социаль-шәхси, танып белү-сөйләм, нәфис-нәфасәти үсеш юнәлешләре буенча төрлеяклап үстерү;
*Балаларның иҗади сәләтен ачу, сәләтлеләрне табу, шәхси үстерү өчен яңа технологияләр куллану;
*Балаларның мөмкинчелегеннән, кызыксынучанлыгыннан, сорауларыннан чыгып төрле төр эшчәнлекләрне үстерү;
*Эчтәлекле аралашуга, сөйләшүгә төзелгән шәхси һәм төркем белән эшчәнлекләр оештыру;
*Балага эшчәнлектә үзен күрсәтү, эш эчтәлеген, эш төрләрен, эштә иптәш сайлау хокукы бирү.

## 1 нче төркем турында белешмә

1 нчы мәктәпкә әзерлек төркеме – татар төркеме. Төркемдә 15 бала: 7 кыз һәм 8 малай йөри. Төркемдә - 6-7 яшьлек балалар.

### Төркемнең социаль паспорты

| 9 нчы төркем | Сан | % |
|---|---|---|
| Әти-әниләр саны | 40 | 100 |
| Гаилә составы:<br>Тулы<br>Тулы булмаган<br>Күп балалы<br>Уңышлы<br>Социаль яктан уңышсыз | 14<br>12<br>2<br>2<br>14<br>- | 100<br>86<br>14<br>14<br>100 |
| Белем цензы (укымышлылык дәрәҗәсе)<br>Югары<br>Ур.- проф.<br>Урта | <br>22<br>6 | <br>79<br>21 |
| Балалар күләме | 14 | 100 |

| | | |
|---|---|---|
| Шул санда (гаилә)<br>- татар милләтле | 14 | 93 |

**6-7 яшьлек балаларның психик үсешенең яшь үзенчәлекләре.**

Сюжетлы-рольле уеннарда җиденче яшькә чыккан балалар өлкәннәрнең әһәмиятле тормыш вакыйгаларын чагылдыручы катлаулы мөнәсәбәтләрен үзләштерә башлыйлар. Мәсәлән, туй, бала туу, авыру, эшкә урнашу һ.б. Бу каршылык мәктәпкәчә яшьтәгеләр эшчәнлегенең төп төре булган уен аша чишелә.

Уен элементлары катлаулана, олы кешегә һәрвакытта да ачылып бетми торган мәгънә ала бара. Уен пространствосы катлаулана. Анда берничә үзәк булып,һәркайсының үз сюжет сызыгы була. Шул ук вакытта балалар белән бергә уйнаган иптәшләренең үз -үзләрен тотышын барлык уен пространствосы буйлап күздән ычкындырмаска кирәк. Мәсәлән, бала кибетчегә сатып алучы буларак кына түгел, ә сатып алучы әни яки сатып алучы шофер буларак мөрәҗәгать итә.

Балаларның сынлы сәнгать эшчәнлегендә әйләнә -тирә тормыштан һәм әдәби әсәрләрдән алып сүрәтләгән образлары катлаулана бара. Рәсемнәр детальләшкәнрәк характер ала, аларның буяулар гаммасы байый. Кызлар һәм малайлар рәсемнәре арасында аермалык күзгә ташлана. Малайлар бик теләп техника, галәм, сугыш хәрәкәтләре һ.б ясыйлар. Кызлар , гадәттә,хатын-кыз образларын сүрәтлиләр - принцессалар,балериналар, һ.б. Кеше сүрәте тагын да пропорциональ булып бара. Күзләр, авыз, борыннар, кашлар, ияк ясала, кул бармаклары да барлыкка килә. Балалар төзү материалларыннан конструкцияне шактый югары дәрәҗә үзләштерәләр. Алар сурәтләрне, шулай ук корылмаларны анализлауның гомуми алымнарын иркен үзләштерәләр, күләмле таныш предметлар белән охшатып, аларның формасын да билгелиләр. Кабул итү сәләте үсә, ләкин балалар һәрвакытта да әйбернең берничә төрле билгеләрен исәпкә алып бетерә алмыйлар. Образлы фикерләү сәләте үсә, ләкин үлчәм мөнәсәбәтләрен кабаттан торгызу бала өчен авырлык тудыра. Уйлап чыгару сәләте дә үсә, ләкин бу зурлар төркеме белән чагыштырганда, шактый түбән. Моны төрле йогынтылар белән аңлатырга була.

Балаларның игътибарлылыгы арта бара. Алар кайбер эшчәнлек вакытында 30 ар минут игътибарлыкларын туплап утыра алалар. Балаларның сөйләме, аның аваз ягы, грамматик төзелеше, лексикасы үсә. Бәйләнешле сөйләмнәре дә шомара. Балалар актив рәвештә гомумиләштерүче исемнәр, синонимнар, антонимнар, сыйфатлар куллана башлыйлар. Мәктәпкә әзерлек төркемендә мәктәпкәчә чор тәмамлана. Балалар кешеләр белән позитив аралашу формаларын үзләштерәләр, укучы позициясе формалаша.

**1.5 Ел ахырына үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр.**

***"Физик үсеш" белем бирү өлкәсе.***

Гәүдәне төз тотып, төрле юнәлештә җиңел рәвештә йөри, йөгерә.

Темпны үзгәртеп 2.5 м биеклектәге гимнастика стенкасына үрмәләп менә.

20 см биеклектән йомшак өслеккә сикерү; 30 см биеклектән билгеләнгән урынга; баскан җирдән озынлыкка (кимендә 80 см); йөгереп килеп озынлыкка (кимендә 100 см); йөгереп килеп биеклеккә (40 см тирәсе) сикерү; кыска һәм озын сикергеч бау аша сикерү.

Уң кул белән 5—9 м ераклыкка ыргыту; 3—4 м ераклыктагы горизонталь һәм вертикаль ноктага ыргыту; тупны югарыга чөю, җиргә бәрү һәм бер кул белән тотып алу; тупны кимендә 10 мәртәбә рәттән җиргә бәреп тору; тупны җирдә сикертә-сикертә бару (ара 6 м).

Статик һәм динамик тигезлекне саклау күнегүләре башкару.

Өчәрләп, дүртәрләп колоннага күченеп тезелү; колоннада, шеренгада баш артына карап тигезләнү, уңга, сулга, тулы әйләнеш ясап борылу.

Гомуми үсеш күнегүләрен башлангыч торышка дөрес басып башкару; аларның сәламәтлек өчен файдасын төшендерү.

Төрле биремнәр үтәп, боздан шуу.

Аякларны шудыра-шудыра, чаңгыда йөрү (2 км тирәсе);

Самокатта йөрү.

Спорт уеннары элементлары кергән күнегүләр башкару.

Үз шкафында тәртип саклый, тиз рәвештә чишенә, киенә.

Чисталык алымнары үзләштерелгән.

Культура-гигиена күнекмәләре формалаштырылган (үзе тешләрен чистарта, кулын юа, төчкергәндә авызын тота)

Ашаганда әдәпле булу кагыйдәләрен белә, пычак, чәнечке белән куллана.

Сәламәт яшәү чыганаклары турында күзаллаулары формалаштырылган.

Кеше сәламәтлегенә иртәнге зарядканың, чыныгуның, көндәлек режимның файдасын белә.

Мөстәкыйль рәвештә киенә, чишенә, юеш киемнәрен киптерә, аяк киемнәре артыннан карый.

Ашаганда дежур тору вазифаларын үти, дөрес итеп өстәлдә сервировка ясый.

Төркем бүлмәсендә һәм мәйданчыкта тәртипне саклый.

Табигать почмагында вазифаларын үти.

**Социаль- аралашу" белем бирү өлкәсе.**

Партнерлар белән нинди уен уйнаячаклары, кем нинди роль башкарачагы турында фикерләшү; уен кагыйдәләренә буйсыну.

Уенда катнашучыларның санына карап, уенның эчтәлеген киңәйтү.

Уен эчтәлеген баетуга булышлык итүче төрле мәгълүмат чыганакларыннан (кино, әдәбият, сәяхәтләр һ.б.) файдалану.

Уенчыкларны алыштыручы предметлар, функцияле материаллар кулланып, иҗади предметлы уен мохите булдыру.

Дидактик уеннарда үз мөмкинлекләреңне бәяли белү һәм отылуны кызып китмичә кабул итү.

Яшьтәшләренә уен кагыйдәләрен аңлату.

Спектакль караганнан соң актерның (актерларның) уенын, кулланылган сәнгать чараларын һәм постановканың сәнгатьле бизәлеш элементларын бәяли белү.

Балалар бакчасында һәм өй театрында берничә роль уйнау, төрледән-төрле материал (атрибутлар, кул астындагы материал, эшләнмәләр һ.б.) кулланып, үз спектаклеңне бизәү.

Уен кагыйдәләрен аңлату; яшьтәшләренең җавапларын, әйткән фикерләрен дусларча һәм дәлилләр китереп бәяләү.

Балалар бакчасында элементар куркынычсызлык кагыйдәләрен үти.

Урамда, транспортта, юлда элементар куркынычсызлык кагыйдәләрен үти.

"Ашыгыч ярдәм", "Янгын сүндерүче", "Полиция" машиналарын танып әйтә, файдалануларын аңлата.

Светофор билгеләрен аңлый. "Җәяүлеләр юлы", "Балалар", "Трамвай тукталышы", "Автобус тукталышы", "Ашыгыч ярдәм ноктасы" билгеләрен белә.

Машиналар йөри торган, җәяүлеләр йөри торган, җир астыннан йөри торган юл йөрү өлешләрен аера.

Табигатьтә үзеңне тоту чараларын белә.

**"Сөйләм үсеше" белем бирү өлкәсе.**

Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр куллану; туры һәм кыек сөйләмнән файдалану.

Үз тәҗрибәсеннән чыгып, сюжетлы рәсемнәр, картиналар тупламасы буенча мөстәкыйль рәвештә хикәяләр төзү; әкиятләрнең ахырларын тәмамлау; зур булмаган әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйли белү.

Сүздә авазның урынын билгели белү.

Исемне берничә сыйфат белән яраштыра белү; сүзне охшаш мәгънәле сүз белән алыштыра белү.

Сөйләмдә кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләренә кагылышлы сүзләр куллану.

Программа буенча 2-3 шигырь белә, 2-3 табышмак, 2-3 санамыш белә.

Әсәрнең жанрын атый.

Күләме зур булмаган әкиятләрне сәхнәләштерә, рольләргә бүленеп шигырьләр укый.

Яраткан балалар язучысын әкиятләрен, хикәяләрен атый.

**“Нәфис - нәфасәти” белем бирү өлкәсе.**

Сынлы сәнгать әсәрләре белән кызыксынуларын уяту (рәсем сәнгате, китап графикасы, халык декоратив сәнгате).

Сәнгатьнең төрләрендә тәэсирле (үтемле) чараларны күрсәтә белү (форма, төс, колорит, композиция).

Сурәтләү өчен кулланыла торган материалларның үзенчәлекләрен белү.

*Рәсем ясауда*

Предмет рәсемнәре ( күзаллап, натурадан карап), сюжетлы рәсемнәр (әйләнә-тирәдәге тормыш, табигать күренешләре, әдәби әсәрләр темаларына) иҗат итү; төрле композиция чишелешләре, сурәтләү материаллары куллану.

Сәнгать образлары тудырганда, төрле төс һәм төсмерләр куллану.

Халык декоратив-гамәли сәнгать мотивлары буенча бизәкләр төшерә белү; бизәкләр ясау өчен төрле ысул һәм элементлар куллану, декоратив сәнгатьнең теге яки бу төренә туры килгән төсләр сайлау.

*Әвәләп ясауда*

Элек өйрәнгән алым һәм ысулларны кулланып, төрле формадагы предметларны әвәләп ясау.

Фигураларның пропорцияләрен, торыш һәм хәрәкәтләрен чагылдырып, зур булмаган сюжет композицияләре төзү.

Халык уенчыклары мотивлары буенча сурәтләр тудыру.

*Кисеп ябыштыруда*

Кисүнең төрле ысулларын, шулай ук ерткалап ябыштыру алымын кулланып, предметларны сурәтләү һәм катлаулы булмаган сюжет композицияләре иҗат итү.

Музыкаль әсәрләрнең жанрларын (марш, бию, җыр) аера белү, музыка уен коралларының тавышларыннан (фортепиано, скрипка), әсәрләрне көеннән, кереш өлешеннән таный белү.

Югары һәм түбән авазларны аера белү (квинта эчендә).

Тавышны көчәйтмичә, салмак, җиңел тавыш белән, сүзләрне ачык һәм төгәл әйтеп, музыка уен коралларына кушылып, бердәм башлап җырлый һәм тәмамлый белү.

Музыканың динамик төсмерләренә, характерына туры китереп, ритмик рәвештә хәрәкәт итә белү.

Өч кисәктән торган музыкаль әсәрнең төзелешенә һәм музыкаль фразаларның характерына туры китереп, мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтләрне үзгәртә белү.

Ел дәвамында үзләштерелгән бию хәрәкәтләрен башкара белү.

Мөстәкыйль рәвештә җырларның, түгәрәк уеннарының эчтәлеген сәхнәләштерү, бер-берсенә охшарга тырышмыйча хәрәкәт итә белү.

Аерым-аерым һәм зур булмаган төркемнәргә бүленеп металлофонда көйләр уйный белү.

**“Танып белү” белем бирү өлкәсе.**

*Иң гади математик күзаллауларын формлаштыру.*

Предметларны төркемли, төркемнәрне чагыштыра белә, бөтен әйберләрнең үз кисәкләреннән зуррак булуын аңлату.

10 эчендә тәртип буенча санау.

Микъдар һәм тәртип саннарын дөрес куллану, «Ничә?», «Ничәнче?» сорауларына дәрес җавап бирә белү.

10 эчендә янәшә торган саннарны чагыштыру (күрсәтмә материал ярдәмендә), кайсы санның зуррак (кечерәк) булуын белү. Азрак булган төркемгә бер предметны өстәп һәм күбрәк булган төркемнән бер предметны алып, саннарны тигезли белү.

Күз күреме белән предметларны чагыштыра (озынлыгы, киңлеге, биеклеге; юанлыгы буенча) белү; берсе өстенә икенчесен кую һәм, янәшә кую ысулларыннан файдаланып, әлеге чагыштырып әйтелгәннәрнең төгәллеген билгеләү.

Төрле зурлыктагы предметларны 7—10 га кадәр чагыштыру (озынлыгы, киңлеге, биеклеге арта бару тәртибендә); предметлар зурлыгының чагыштырма төшенчә булуын аңлау.

Предметлар һәм кешеләр арасында үз торышыңны билгели белү; шулай ук бер предметның икенчесенә карап торышын билгеләү.

Таныш геометрик фигураларның кайбер характерлы үзенчәлекләрен (почмакларның, якларның саны; якларның тигез булуы, тигезсезлеге) белү.

Предметларның формасын (түгәрәк, өчпочмаклы, дүртпочмаклы) белү.

Тәүлек вакытларын (иртә, көндез, кич, төн) эзлекле итеп әйтә белү.

Атнаның агымдагы көнен әйтә белү.

*Бербөтен дөнья картинасын формалаштыру*

Транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә торган предметларны белә.

Әйберләрне ясалыш материаллары буенча классификацияли.

Үз шәһәренең исемен, дәүләтнең, башкаласының исемен белә.

Ел фасылларын белә, аларның үзенчәлекләрен аңлата.

Кояшның, һаваның, суның кеше тормышына әһәмиятен белә.

Табигатькә карата сакчыл караашта.

## II. Эчтәлек өлеше.

### 2.1 *Тәрбия һәм белем бирү процессының эчтәлеге*

Вакыт илебезнең мәгариф учреждениеләре эшенең яңа иҗтимагый-икътисади шартларда алып барылыу мәктәпкәчә мәгарифне заман таләпләренә туры китереп үзгәртүне, дәүләт һәм гаиләнең бала тәрбияләүдәге ролен яңа прогрессив формалар белән баетуны, һәр баланың эмоциональ иминлеге һәм төрле яклы үсеше өчен педагогик коллективның җаваплылыгын арттыруны таләп итә. Бүгенге мәктәпкәчә мәгарифнең приоритетлары үзгәрү сәбәпле балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программаларын яңартырга кирәкле булды. Мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләре, яңа заман таләпләрен исәпкә алып, башка концептуаль нигезендә төзелгән программалардагы мәсьәләләрне һәм эчтәлекне әлеге документка мөстәкыйль рәвештә кертәләр. Программа Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының (23.11. 2009) 655 нче номерлы боерык нигезендә расланган “Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасы структурасына федераль дәүләт таләпләре” (алга таба ФДТ.),Татарстан республикасының 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган телне өйрәтүне, сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру юнәлешен тормышка ашыру максатын күздә тотып төзелде. Шулардан чыгып, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбия һәм белем процессында“Физик үсеш”, “Сөйләм үсеше”, “Социаль-аралашу”, “Танып белү”, “Нәфис-нәфасәти үсеш” юнәлешләре булуы мөһим.

**Региональ укыту методик комплектын тормышка ашыру өчен вариатив өлеш**

Мәктәпкә әзерлек төркеме өчен программа, 6 яшьтән 7 яшькә кадәр чорында тәрбия, белем бирү һәм үсешенең барлык төп юнәлешләрен чагылдыра. Белем бирү процессы “Туудан мәктәпкә кадәр” якынча балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы нигезендә төзелгән, Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева мөхәррияте астында, 2012 ел, 2-е басма, «Балалар бакчасы һәм гаилә өчен ана теле программасы» Ф.Ю. Юсупова, З.Ф. Камалова, Р.А.Борһанова, Мәгариф-1986;

- Зарипова З.М., “Туган телдә сөйләшәбез” 5-7 яшьлек балаларны татар телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек. 2012 ел;
- «Гаиләдә, балалар бакчасында әдәплелек тәрбияләү программасы» К.В. Закирова, Р.А. Низамов, Мәгариф-2006;
- “Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы”, Р.К.Шаехова, 2012;

***Программаның төп максатлары:***

- һәр баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яклы үсеш алуы турында кайгырту;

- балаларны аралашучан, игелекле, кызыксынучан, инициативлы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып, төркемнәрдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру;

- балалар эшчәнлеген төрле төрләрен киң куллану, укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны интегральләштерү;

- тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;

- балаларның мөмкин булганча төрле эшчәнлекләрен файдаоану, белем бирү процеммын нәтиҗәлерәк итү максатында аларны берләштерү;

- мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү оешмасы һәм гаилә шартларында бала тәрбиясенә якын килүгә юнәлеш бирү;

-гаиләнең балалар бакчасы төркемнәре һәм мәктәпкәчә оешманың тормышында катнашуын тәэмин итү;

- балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балага кирәклеген артык акыл һәм физик эш йөкләмәү максатыннан дәвамчынлыкны саклау;

- региональ якын килүне гамәлгә ашыру;

**2.2 Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге (мәктәпкә әзерлек төркемендә белем бирү өлкәләренең төп максатлары һәм бурычлары)**

**<u>Физик үсеш белем бирү өлкәсе.</u>**

Балаларның сәламәтлеген ныгыту өстендә эшләүне дәвам итү: организмны чыныктыру, төп хәрәкәтләрне камилләштерү, барлык эшчәнлек төрләрендә гәүдәне дөрес, төз тоту гадәтен ныгытырга игътибар итү, гигиеник күнекмәләр һәм гәүдә рефлексиясе тәрбияләү. Мөстәкыйльлекләрен, иҗади сәләтләрен үстерү. Матур сынлы, зифа, төз гәүдәле булуларына омтылыш тәрбияләү.

**Балаларның психик һәм физик сәләмәтлекләрен саклау һәм ныгыту.**

Медицина хезмәткәрләре күзәтүе астында һава, кояш, суда чыныктыруны физик күнегүләр белән бергә үреп бару.

Көн саен 8—10 минутлык иртәнге гимнастика, көндезге йокыдан соң физик күнегүләр белән берлектә һава процедуралары үткәрү.

Зур акыл эшчәнлеге таләп ителгән дәресләрдә 1—3 минутлык физкультминутлар уздыру.

Балаларны мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтле, спорт уеннары оештырырга; һавада йөргәндә, булган уенчыклар һәм физкультура җиһазларыннан файдаланып, физик күнегүләр башкарырга: кышын чанада, бозда шуарга, чаңгыда йөрергә; җәен ике көпчәкле велосипедта, роликлы тимераякта, самокатта йөрергә өйрәтү. Шартлар булганда, балаларны йөзәргә һәм гидроаэробика элементлары өйрәтүне оештыру.

Спорт бәйрәмнәре, күңел ачу кичәләре вакытында балаларны күмәк уеннарда, ярышларда актив катнашырга, кыю, җитез, чыдам, тапкыр булырга өйрәтү.

Физкультура-сәламәтләндерү эшләре процессында физик, психик, әхлакый сыйфатлар тәрбияләү, мөстәкыйльлекләрен, иҗади сәләтләрен үстерү.

**Культура-гигиена күнекмәләрен тәрбияләү.**

Балада үзен чиста, киемен һәм чәчен пөхтә йөртү гадәте тәрбияләү. Тешләрне, аяк-кулны чиста йөртүнең сәламәтлек өчен ни дәрәҗәдә мөһим булуын төшендерү. Һәр көн иртән һәм кичен ни өчен тешләрне чистартырга кирәклеген (чөнки теш арасында калган ризык калдыклары микроблар барлыкка китерә һәм теш сызлый башлый); ни өчен кул һәм аяк тырнакларының һәрчак кыска итеп киселгән булырга тиешлеген (чөнки кулда бик күп бактерияләр «яши») һ.б. аңлату. Мөстәкыйль рәвештә тешләрен чистартырга, тырнакларын кисәргә өйрәтү. Йөткергәндә, төчкергәндә авызны кульяулык белән каплап читкә борылуга гадәтләндерү. Тиз, пөхтә итеп киенергә, чишенергә өйрәтү, үз шкафын тәртиптә тотарга күнектерү.

Ашау-эчү приборларыннан (чәнечке, пычак) дөрес файдалану, өстәл артында дөрес утырган хәлдә түкми-чәчми, тыныч ашарга өйрәтеп, балаларның ашау күнекмәләрен камилләштерү

**Сәламәт тормыш нигезләрен формалаштыру.**

Кеше организмы турында күзаллауларын тулыландыру. организмның үзенчәлекләренә басым ясау (“Миңа апельсин ашарга ярамый – миндә аллергия”, “Миңа күзлек кияргә кирәк”)

Сәламәтлекнең әһәмиятен аңлату, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү өчен шартлар тудыру.

Кешенең сәламәтлеге аның дөрес туклануы белән бәйле икәнен аңлату, ризыкларның сыйфатларын сенсорик тойгылар ярдәмендә билгеләү.

Көндәлек тормышта гигиена күнекмәләрен үтәүгә һәм пөхтәлек булдыруга ихтыяҗ формалаштыру.

Авырулар артыннан карау кагыйдәләре белән таныштыру, аларга карата кайгыртучанлык тәрбияләү.

Кеше сәламәтлегенең мөмкинлекләре белән таныштыру. Сәламәт яшәү ихтыяҗы формалаштыру.

Спорт залда һәм спорт площадкада куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштыру.

Шөгыльләрдә кызыксыну һәм аңлы караш, гармонияле физик үсеш формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтә һәм түбәндәге белем бирү бурычларын билгели:

- психофизик сыйфатлар тәрбияләү;
- балаларның хәрәкәт тәҗрибәләрен туплау;
- хәрәкәт ихтыяҗы формалаштуру;

**Физик сыйфатлар үстерү, хәрәкәт тәҗрибәсен тулыландыру.**

Балаларның хәрәкәт күнекмәләрен камилләштерү.

Тизлек, көч, чыдамлык, сыгылмалылык һ.б. шундый психо- физик сыйфатларын үстерү.

Таяну ноктасыннан көч белән этелеп, җиңелчә йөрү һәм йөгерү күнекмәләрен ныгыту. Каршылыкларны үтеп, куышып йөгерергә өйрәтү.

Темпны үзгәртеп, гимнастика стенасына үрмәләп менәргә өйрәтү. Йөгереп килеп озынлыкка, биеклеккә сикерергә һәм дөрес итеп җиргә төшәргә өйрәтү; озын сикергеч бау аша сикерү, йомшак түшәмәгә төшкәндә тигезлекне саклау.

Ыргыткан вакытта селтәнүне ыргылыш белән бергә туры китерергә, тупны бер кул белән ыргытырга һәм тотып алырга, аны бер урында уң һәм сул кул белән бәреп торырга, бәрә- бәрә алып барырга өйрәтү.

Чаңгыда шудырма адым белән йөрү, тауга менү һәм төшү; ике көпчәкле велосипедта йөрү; бер аяк белән {уң һәм сул) этелеп, самокатта йөрү. Тирәлектә ориентлашырга өйрәтү.

Спорт уеннары, ярыш элементлары кергән уеннар,уен- эстафеталарга өйрәтү.

Өлкәннәргә дәресләр, физик күнегүләр башкару өчен физкультура җиһазлары әзерләргә булышу, ахырдан урыннарына алып кую.

Баланың шәхес буларак һәрьяклы үсешен тәэмин итү, анда физик, акыл, эстетик, рухи, әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.

Балаларның спорт төрләренә булган кызыксынуларын хуплау, илебез тормышындагы спорт вакыйгалары турында кайбер мәгълүматлар биреп бару.

**Төп хәрәкәтләр**

***Йөрү.*** Гадәти йөрү, аяк очларына (кулларны баш артына куеп), үкчәгә, аяк табанының тышкы кырына басып, тезләрне югары күтәреп, йөрүне үкчәдән аяк очларына таба күчереп, бер аякны икенчесе янына күчереп куеп уңга һәм сулга таба йөрү. Тәрбияче биргән төрле биремнәрне үтәп, зал тирәли борылышлар ясап, колоннада берәрләп, икешәрләп, өчәрләп йөрү.

Тигезлекне саклау күнегүләре. Гимнастика эскәмиясенең тар рейкасы һәм бау (диаметры 1,5—3 см) буенча атлау, авыш такта буйлап алга карап, ян белән һәм аяк очларында атлап бару. Гимнастика эскәмиясе буенча анда куелган тупларны атлап үтеп, уртага җиткәч чүгәләп, үз алдында ике кул белән туп тәгәрәтеп, баш өстенә ком тутырылган кечкенә капчык куеп ян белән (бер аякны икенче аяк янына күчереп) йөрү. Авыш такта буйлап өскә һәм аска таба аяк очларында йөрү; ян белән бер аякны икенче аяк янына куеп атлау. Куллар белән тотышып, парлашып әйләнү.

***Йөгерү.*** Гадәти йөгерү. Аяк очларында, тезләрне югары күтәреп, вак-вак һәм киң адымнар белән атлап, тезелеп берәм- берәм, икешәрләп: урап-урап, таралышып, каршылыкларны җиңеп йөгерү. Әкрен темп белән 1,5—2 мин буенча туктаусыз йөгерү; уртача темпта, йөгерүне атлап йөрүләр белән алыштырып, 80—120 метрга (2—3 тапкыр) йөгерү; 3 тапкыр 10 ар метр арлы-бирле (челночный) йөгерү. Тизлеккә йөгерү: 20 м араны якынча 5,5—5 секундта узу (ел ахырына 30 м ны — 7,5—8,5 секундта).

***Шуышу, үрмәләү.*** Йөрү, йөгерү, каршылыклар аша үтүне чиратлаштырып, предметлар арасыннан урап-урап шуышу; баш белән тупны этә-этә шуышу (ара — 3—4 м); беләкләргә һәм тезләргә таянып, корсакта, куллар белән тартыла-тартыла гимнастика эскәмиясендә шуышу. Рәттән берничә предмет аркылы чыгу, төрле ысуллар белән кыршауга үрмәләп керү, темпны үзгәртә-үзгәртә гимнастика баскычына (биеклеге 2,5 м) үрмәләп менү, бер аралыктан икенче аралыкка үрмәләп чыгу, рейкалар арасыннан үрмәләп үтү.

***Сикерүләр.*** Йөрү белән чиратлаштырып, бер урында ике аякта сикерү (30—40 мәртәбә); төрле ысуллар белән (аякларны чалыштырып, аерып, бер аякны алга, икенчесен артка куеп), алга таба хәрәкәтләнеп (3—4 м ара) сикерү. Бер аяк белән (уң һәм сул) урында һәм алга таба хәрәкәтләнеп; басып торган урыннан турыга һәм янга, 5—6 предметның һәрберсе аша чиратлаштырып биеклеккә (15—20 см) сикерү. 20 см биеклектән йомшак түшәмәгә, 30 см биеклектән билгеләнгән урынга, басып торган урыннан озынлыкка (кимендә 80 см), йөгереп килеп озынлыкка (100 см тирәсе), йөгереп килеп биеклеккә (30—40 см) сикерү. Алга һәм артка әйләндереп, кыска сикергеч бау аша сикерү; хәрәкәтсез һәм әйләнеп торган озын сикергеч бау аша сикерү.

***Ыргыту, тотып алу, чөю .*** Тупны югарыга чөю, җиргә бәрү һәм аны ике кул белән тотып алу (рәттән кимендә 10 тапкыр); бер кул белән (уң, сул кул белән кимендә 4—6 тапкыр) тотып алу; тупны югары чөю һәм кулны чәбәкләп тотып алу. Тупны бер кулдан икенче кулга, бер-берeeнә төрле торыштан һәм төрлечә тезелгән хәлдә, төрле ысуллар белән (астан, баш артыннан, күкрәк турысыннан, җирдән сикертеп) ыргыту. Бер урында алга таба атлый-атлый (5—6 м га кадәр) тупны җирдә сикертү, эченә әйбер тутырылган тупны тәгәрәтү (авырлыгы 1 кг). Предметларны ераклыкка (кимендә 5—9 м га), 3—4 м ераклыктагы горизонталь һәм вертикаль ноктага (мишень үзәге 1 м биеклектә) ыргыту.

***Тезелү күнегүләре.*** Берәрләп колоннага, бер рәткә тезелү. Колоннага икешәрләп, өчәрләп күченеп тезелү; баш артына карап, колоннада, бер рәттә тигезләнү. Колоннада — кулларны алга сузып, рәттә — кулларны янга сузып сирәкләнү; уңга, сулга һәм тулы әйләнеш ясап (кругом) атлап, сикереп борылу.

***Ритмик гимнастика.*** Таныш күнегүләрне матур, нәзакәтле итеп музыка астында башкару. Хәрәкәтләрнең ритмын музыка әсәре белән яраштыру.

***Гомуми үсеш күнегүләре***

Кул чукларын һәм иңбаш мускулларын ныгыту, үстерү күнегүләре. Кулларны күкрәктәй янга сузу; өскә күтәрү һәм баш артыннан учларны өскә каратып янга сузу. Бер кул бармакларың икенче кулныкылар арасына кертеп («бик» ясап), кулларны алга-өскә күтәрү (уч түбен тышка каратып); кулларны чиратлаштырып һәм берьюлы өскә-артка күтәрү. Кул чукларын күтәрү һәм төшерү; бармакларны йому һәм җәю.

***Арка мускулларын ныгыту һәм үстерү, умыртка баганасының сыгылмалылыгын арттыру күнегүләре.*** Стенага баш арты, иңбашы, җилкә, аяклар белән терәлеп басып торган хәлдә, кулларны өскә күтәрү һәм аска төшерү. Гимнастика баскычына арка белән терәлгән хәлдә, бил биеклегендәге рейкасына тотынып, тездән бөгелгән аякларны чиратлаштырып күтәрү. Гимнастика баскычына таба карап баскан килеш, бил биеклегендәге рейкасына тотынып алга иелү; учлар белән идәнгә таянырга тырышып алга иелү; кулларны арка ягында (артта) бергә кушып иелү. Кулларны күкрәктән ян-якка җибәреп, баш артына куеп борылу. Чүгәләп, аякларны чиратлаштырып, читкә сузу; аркада яткан хәлдә аякларны чалыштырып хәрәкәтләндерү. Баш һәм аякны күкрәккә китерү (бөгәрләнү); гимнастика эскәмиясендә куллар белән күтәрелү.

***Корсак прессы һәм аяк мускулларын ныгыту, үстерү өчен күнегүләр.*** Аяк очларын идәннән аермыйча, үкчәләрне күтәреп бер урында атлаган кебек итү. Кулларны алга сузып, өскә күтәреп, артка куеп чүгәләү (һәр эшләгән саен түбәнрәк чүгәли барып). Турайтылган аякларны өскә күтәрү (бик тиз); алга, янга бөгелү (кулларны билгә куеп, алга, янга, өскә кул хәрәкәтләре ясап).

Предметларны аяк бармаклары белән эләктереп, бер урыннан икенче урынга этеп күчерү. Аяк очлары белән канатка, үкчәсе белән идәнгә басып, аякларны чиратлаштырып күчереп, янга бару.

***Статик күнегүләр.*** Гимнастика эскәмиясендә аяк очларына басып, аяк очларында чүгәләп; тотрыклылыкны саклап йөгерү һәм аяк очларында чүгәләп, куллар як-якка сузылган хәлдә, сикерүләрдән соң бер аякта басып, кулларны билгә куеп тотрыклылыкны саклап калу.

**<u>Социаль-аралашу белем бирү өлкәсе</u>**

Балаларның социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтә һәм белем бирү бурычларын билгели:

- уен эшчәнлеген үстерү;
- җәмгыятьтә кабул ителгән нормаларны үзләштерү;
- Гаилә, берләшмә, гражданлык төшенчәләрен аңлату, патриотик хисләр тәрбияләү.

**Уен эшчәнлеген үстерү**

***Сюжетлы-рольле уеннар.***

Балаларның уен күнекмәләрен киңәйтү, камилләштерү. Сюжетлы-рольле уеннар оештыра белү күнекмәләре формалаштыру. Фикерләү эшчәнлеген активлаштыру, иҗат активлыгын үстерү. Балаларның мөстәкыйль рәвештә уен темасын сайлый белүләрен үстерү: әйләнә-тирә белән танышу, әдәби әсәрләр уку, телевидение тапшырулары караудан алган белемнәргә таянып, уеннарның сюжетын үстерү, тематикасын баету.

Уен башланганчы башкалар белән аның темасы турында фикерләшергә, рольләрне бүлешергә, кирәкле шартлар тудырырга өйрәтү. Уенда рольгә керергә һәм рольләр арасындагы үзара бәйләнешне аңларга булышлык итү. Үзара дуслык мөнәсәбәтләре формалаштыру.

Уен вакытында килеп чыккан бәхәсләрне мөстәкыйль чишә белергә өйрәтү. Үз гамәлеңне башкаларныкы белән яраштыра белү күнекмәләре бирү. Уен кагыйдәләрен сакларга өйрәтү. Уенда катнашучылар күбрәк булган саен, аның эчтәлеге баерак, уен күңеллерәк булачагын төшендерү. Яңалыклар кертеп (атрибутларны үзгәртү, өлкәннәрнең катнашуы, алмаш предметлар куллану, уенның барышын үзгәртү) уенның эчтәлеген баету.

Төрле тематик сюжетларны бер сюжетка берләштерә белү күнекмәләре бирү.

Уен өчен кирәкле корылмаларны күмәкләшеп төзергә, алда торган эшне бергәләшеп планлаштырырга һәм ул эшне бергәләп башкарырга гадәтләндерү. Шөгыльләрдә үзләштергән конструкторлык белемнәрен кулланырга, пластмасса, агач, металл конструкторлардан файдаланырга өйрәтү.

Уен тәмамланганнан соң, уенчыкларны урыннарына куярга гадәтләндерү.

***Сәхнәләштерелгән уеннар***

Балаларның үзләре белгән әкиятләр, шигырьләр, җырлар буенча тамашалар уйнау осталыкларын үстерүне дәвам иттерү, бу максатларда төрле курчак, бибабо курчаклары, кулдан ясалган уенчык, атрибутлар, костюмнардан, декорацияләрдән файдалану. Башкару осталыкларын камилләштерү.

Әсәр геройларының эчке кичерешләрен, эмоциональ халәтен аңларга өйрәтү, башка персонажлар белән рольгә керә белү күнекмәләре бирү.

Спектакльләр, концертлар әзерләү һәм аларны үткәрү өчен иҗади төркемнәр оештырырга өйрәтү.

Сәхнәләштерелгән төрле чараларга катнаштырып (концерт куеп, цирк күрсәтеп уйнау, спектакльләрдән өзекләр күрсәтү һ.б.), балаларның иҗади мөмкинлекләрен, сәләтләрен ачу. Балаларга яшьтәшләре, әти-әниләре һәм башка кунаклар алдында чыгыш ясау мөмкинлеге бирү.

***Хәрәкәтле уеннар***

Таныш уеннарны мөстәкыйль рәвештә оештыра белергә өйрәтү эшен дәвам итү. Уенны ахырга кадәр уйнау. Балаларда ярыш элементлары кергән уеннарда, уен-эстафеталарда катнашу теләге уяту. Спорт уеннары уйнау, спорт күнегүләре башкару.

***Дидактик уеннар***

Балаларның табигать, иҗтимагый тормыш күренешләре, әйләнә-тирә мохит турындагы белемнәрен системалаштыру һәм баету.

Балаларны кечерәк төркемнәргә берләштереп (2—4 әр бала), мөстәкыйль рәвештә дидактик уеннар оештырырга, кагыйдәләрне төгәл үтәргә өйрәтү.

Балаларның хәтер, игътибар, хыяллана белү, фикерләү, сенсорик сәләтләрен үстерү. Предметларны чагыштырырга, алар арасындагы (төсе, формасы, зурлыгы, материалы) кечкенә генә аерымлыкларны да күрә белергә, гомуми билгеләре буенча берләштерергә, кисәкләрдән бөтен әйбер (җыелма шакмаклар, мозаика, төсле таяклар) төзергә, предметларның урнашу- ларындагы үзгәрешләрне (алда, артта, сулда, уңда, аста, өстә, уртада, янда) билгеләргә өйрәтү.

Төрле дидактик уеннар һәм уенчыклар белән (халык уеннары һәм уенчыклары, электрон һәм компьютер уеннары һ.б.) эш итә белү күнекмәләрен формалаштыру.

Күмәкләшеп уйнаган вакытларда кагыйдәләргә буйсына белергә өйрәтү. Мөстәкыйльлекләрен, иҗади мөмкинлекләрен үстерү. Дуслык, татулык хисләре тәрбияләү. Уен-ярышларда гадел булырга өйрәтү.

**Әхлак тәрбия нормалары белән таныштыру.**

Балалар арасында дустанә мөнәсәбәт булдыру: бергәләп уйнау, шөгыльләнү, төрле эшләр башкару һ.б. Өлкәннәрне үзеңнең яхшы гамәлләрең белән сөендерү.

Башкаларга карата ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү. Үзеңнән кечкенәләр турында кайгырту, аларга ярдәм итү, көчсезләрне яклау.

Яшьтәшләренең кичерешләренә игътибарлы булырга, ярдәм күрсәтергә, үзенең һәм иптәшләренең уңышларына шатлана, уңышсызлыкка очраганда хәленә керә белергә өйрәтү.

Әдәпле сөйләм күнекмәләре булдыру. Ягымлы сүзләр («Исәнмесез», «Сау булыгыз», «Зинһар», «Гафу итегез», «Рәхмәт» һ.б.) исәбенә балаларның сүзлек байлыгын арттыру. Сөйләмдә халык авыз иҗатын файдалану күнекмәләре бирү (мәкальләр, әйтемнәр, эндәшләр һ.б.). Әхлак сыйфатлары булдыруда туган телнең әһәмиятен күрсәтү.

Малайларда кызларга карата игътибарлы мөнәсәбәт тәрбияләү: урындык бирү, кирәк чакта ярдәмгә килү, кызларны биергә чакырырга оялмау һ.б.

Кызларда тыйнаклык тәрбияләү, янәшәдәге кешеләр турында кайгыртучан мөнәсәбәттә булу, малайлар тарафыннан күрсәтелгән ярдәм яки игътибарга рәхмәтле була белергә өйрәтү.

Балаларны яшьтәшләренең кылган эшләренә мөнәсәбәтен белдерергә, үзе һәм иптәшләре кылган эшкә дөрес бәя бирергә өйрәтү.

**Гаилә, берләшмә, гражданлык төшенчәләрен аңлату, патриотик хисләр тәрбияләү.**

***Мин*** образын формалаштыру (балага аның яхшы яклары, аның нинди әйбәт бала булуы, һәркемнең аны яратуы турында даими әйтеп тору, ышандыру). Балаларда үз нәселенә карата кызыксыну уяту, бала белән нәсел агачы (шәҗәрә) төзү (әби-бабайдан башлап); туганнарының фоторәсемнәрен карау, әти-әнисе яки туганнары белән тышкы кыяфәтенең охшашлыгын (чәч яки күзләренең төсе) күрә белергә өйрәтү. Балалар әти-әниләренең эш урыннарын белергә, алар хезмәтенең җәмгыять өчен әһәмиятен аңларга тиеш. Өйдә балаларның һәр көн башкарыла торган эшләре — көндәлек вазифалары булуы зарур. Балалар әти-әниләренең, гаиләдәге башка әгъзаларның шөгыльләрен, хезмәтләрен хөрмәтли белергә тиешләр. Балаларга үзе яшәгән йорт һәм фатир номерын, урам-шәһәр (авыл) исемен өйрәтү. Аларны төрле гаилә бәйрәмнәренә әзерлек эшләрендә катнаштыру.

***Гаилә.*** Балаларда үз нәселенә карата кызыксыну уяту, бала белән нәсел агачы төзү, туганнанрының фоторәсемнәрен карау, әти-әнисе яки туганнары белән тышкы кыяфәтеннән охшашлыгын күрә белергә өйрәтү. Балалар әти-әниләренең эш урыннарын белергә, алар хезмәтенең җәмгыять өчен әһәмиятен аңларга тиеш. Балаларга үзе яшәгән йорт һәм фатир номерын, урам-шәһәр исемен өйрәтү. Аларны төрле гаилә бәйрәмнәренә әзерлек эшләрендә катнаштыру.

***Балалар бакчасы***. Балалар бакчасы тирәсендә иркен ориентлаша белү күнекмәләрен камилләштерү. Бакчада үткәрелә торган төрле чараларда катнаштыру.

Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү, юл аркылы светофор сигналы буенча гына чыгарга кирәклеген аңлату.

Балаларга тормыш иминлеге, куркынычсызлык кагыйдәләрен өйрәтү: ут белән шаярмаска, өлкәннәр югында электр приборларыннан файдаланмаска, рөхсәтсез очлы, үткен әйберләрне кулланмаска һ.б. Кирәк булган очракларда мөстәкыйль рәвештә янгын куркынычсызлыгы хезмәте, милиция, «Ашыгыч ярдәм» телефон номерларын (01, 02, 03) җыя белергә өйрәтү.

Өлкәннәр белән бергә башкарган эшләрдән канәгатьләнү алу, шатлану хисе тәрбияләү.

Балаларны яшьтәшләренә карата игътибарлы, кечкенәләр белән кайгыртучан мөнәсәбәттә булырга өйрәтү. Балалар бакчасы хезмәткәрләренә хөрмәт тәрбияләү.

***Туган ил.*** Балаларның туган ил, дәүләт һәм халык бәйрәмнәре турындагы күзаллауларын киңәйтү. Халык традицияләре, йолалары, гореф-гадәтләре белән таныштыру. «Кече ил»гә карата кызыксыну формалаштыру эшен дәвам итү. Туган якның традицияләре, мәдәнияте, истәлекле урыннары турында сөйләү. Россия Федерациясе (Россия) турында мәгълүмат бирү. Картада Россияне, аның күлләрен, елгаларын, диңгезләрен, тауларын, шәһәрләрен күрсәтү. Россиянең башкаласы — Мәскәү шәһәре турында сөйләү. Россиянең флагы, гербы, гимны белән таныштыру.

***Безнең армия.*** Балаларның Армия, Ватанны саклаучылар турында күзаллауларын киңәйтү. Туган илне, аның тынычлыгын, иминлеген саклауның никадәр авыр, ләкин мактаулы хезмәт икәнлеген төшендерү. Бөек Ватан сугышы елларында туган җирен яраткан һәр кешенең батырларча сугышуы һәм илне дошманнардан саклап калуы турында сөйләү. Балалар бакчасына сугыш ветераннарын кунакка чакыру, алар белән әңгәмәләр үткәрү. Балалар белән сугыш тематикасын яктырткан альбомнар, репродукцияләр, картиналар карау.

Күмәк хезмәт эшчәнлегендә катнашасы килү теләге булдыру, төрле хезмәт өлкәләрендә белемнәрен, осталыкларын формалаштыру. Мөстәкыйллек, хезмәт культурасын тәрбияләү. тәрбияләү. Башланган эшне эшләп бетерергә өйрәтү.

***Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү***

Һәр көн саен юыну һәм тешләрен чистарту, ашау алдыннан һәм пычранган саен кулларын юу күнекмәләре бирү.

Билгеле бер эзлеклелектә киенә һәм чишенә, киемне дөрес һәм пөхтә итеп шкафка, аяк киемен үз урынына куя, дымланган киемнәрне вакытында киптерә, аяк киемнәрен карап-чистартып (юу, сөртү, ялтырату) торырга гадәтләндерү.

Үзендәге җыйнаксызлыкны күреп, тәртипкә китерергә, иптәшенә аның өс-баш һәм аяк киемендәге төгәлсезлекне әдәпле итеп кенә искәртергә, аларны бетерүдә булышлык итәргә өйрәтү. Үзара ярдәмләшү тойгысы тәрбияләү.

***Хуҗалык-көнкүреш хезмәте***

Балаларны үз бүлмәләрен һәм мәйданчыкны һәрвакыт тәртиптә тотарга: уенчыкларны, төзү материалларын юып- сөртеп торырга, тәрбияче белән берлектә китап һәм уенчыкларны рәтләргә өйрәтү.

Балалар бакчасы мәйданчыгында мөстәкыйль рәвештә җыештыру эшләре үткәрергә: юлларны себереп, чүп-чардан, кардан чистартырга.

Йокыдан торгач, урын-җирне мөстәкыйль җыештырырга күнектерү.

Табын әзерләү, икенче һәм өченче (җиләк-җимеш) ризыкларны тарату, ашаганнан соң савыт-сабаны җыеп алу, идән себерү кебек дежурлык бурычларын мөстәкыйль һәм намус белән башкарырга гадәтләндерү.

Шөгыль өчен тәрбияче әзерләгән материалларны таратып чыгарга, аларны җыештырырга, пумалаларны, буяу савытларын юарга, өстәлне сөртеп алырга гадәтләндерү.

***Табигатьтәге хезмәт***

Тере почмакта дежур тору бурычларын мөстәкыйль һәм җаваплылык тоеп башкарырга: бүлмә гөлләренә су сибәргә, туфракны йомшартырга, җимлекләрне юарга, азыкны әзерләп (юып, кискәләп) бирергә өйрәтү. Тере почмактагы тереклек ияләре һәм үсемлекләр турында мөстәкыйль кайгыртырга гадәтләндерү.

Көзен балаларны яшелчә һәм орлыкларны җыю, суганча һәм гөл бүлбеләрен казып алу, түтәлләрне казып калдыру, агач һәм куак төпләрен йомшарту, чәчәк атып утыручы үсемлекләрне грунттан алып тере почмактагы чүлмәкләргә күчереп утырту эшләренә тарту.

Кышын агач һәм куак төпләренә кар өю, табигать почмагындагы кошлар һәм башка тереклек ияләре өчен яшел азык үстерү, тамыразык утырту эшенә өйрәтү.

Язын балаларны яшелчә бакчасы һәм чәчәклектәге җирне кабат йомшарту, яшелчә, чәчәк орлыклары чәчү, үрентеләрне (рассада) күчереп утырту эшенә тарту.

Җәен туфракны йомшартып тору, чүп утау һәм үсемлекләрнең төбенә өю, түтәлләргә су сибү эшенә тарту.

***Кул эше***

Кәгазь белән эшләү күнекмәләрен камилләштерү: кәгазьне дүрткә төрле юнәлешләрдә бөкләү; әзер өлге буенча эшләргә өйрәтү (башлык, көймә, өй, акча янчыгы). Кәгазьдән күләмле фигуралар эшләү: квадрат кәгазь битен берничә тигез кисәккә бүлү, бөкләнгән урынны тигезләү, бөкләнгән эздән кисү ( өй, кәрзин, шакмак).

Табигый (нарат, чыршы күркәсе, ботаклар, җиләкләр) һәм башка материаллардан (кәтүк, төсле үткәргечләр, буш тартмалар һ.б.) уенчыклар, сувенирлар ясарга өйрәтүне дәвам итү.

Поролон һәм пенопласттан катлаулы булмаган уенчыклар ясарга өйрәтү (Кар бабай, чеби, кораб һ.б.)

Балаларның иҗади күзаллауларын, зәвыкларын үстерү. Пөхтәлек, кулланылучы материалларга һәм әзер кул эшләренә сак караш тәрбияләү. Эстетик бәяләү формалаштыру.

**Үз хезмәтләрен һәм өлкәннәр хезмәтен бәяли белергә өйрәтү.**

***Өлкәннәр хезмәте.***Өлкәннәр хезмәте турындагы күзаллауларын киңәйтү. Хезмәтнең нәтиҗәләре белән таныштыру, аның кеше тормышында мөһимлеген аңлату. Кеше куллары белән эшләнгән һәр нәрсәгә сак караш тәрбияләү. Ел фасыллары белән бәйле хезмәтләр турындагы белемнәрен системалаштыру.

Педагог, табиб, төзүче, авыл хезмәтчәннәре, транспорт, элемтә, сәүдә, җиңел сәнәгать хезмәткәрләре һөнәрләре турында сөйләү. Кеше хезмәтен җиңеләйтү өчен төрле техника (компьютер, касса аппараты, электр тегү машинасы һ.б.) кулланылуы турында аңлату. Сәнгать әһелләре һөнәрләре: рәссамнар, язучылар, композиторлар, декоратив-гамәли сәнгать осталары белән таныштыру. Аларның хезмәт нәтиҗәләре: картиналар, китаплар, ноталар, декоратив сәнгать эшләнмәләрен күрсәтү.

Кешеләр хезмәтенең түләүле булуы, эшләп тапкан акчаны ризык, кием, йорт җиһазлары алуга, ял итүгә тоту турында сөйләү, аңлату.

Балаларда өлкәннәр белән бергәләп төрле эшләр башкарасы килү теләге уяту. Йөкләнгән эш өчен җаваплылык хисе тудыру. Аны тырышып, җиренә җиткереп башкарырга өйрәтү. Эшләп бетергәннән соң, әйберләрне урыннарына җыеп куярга гадәтләндерү. Материал һәм эш коралларына сак караш тәрбияләү.

Өлкәннәр ярдәме белән, үзенең хезмәт нәтиҗәсен күрә, аны бәяли белергә өйрәтү.

Күмәк эшләрдә башкалар белән беррәттән катнашасы килү теләге, тирә-юньдәгеләр өчен кирәкле кеше булу, билгеле бер нәтиҗәләргә ирешү омтылышы тәрбияләү.

Социаль- аралашу белем бирү өлкәсе. эчтәлеге үз тормышының куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә-тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыруга да юнәлтә һәм белем бирү бурычларын билгели.

***Табигатьтә ял.***

Экологик культура нигезләрен формалаштыру.Табигатьтә барлык әйберләр бәйле икәнен аңлату, ул бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгарырга өйрәтүТере булмаган табигать күренешләре белән таныштыру (күк күкрәү, яшен, салават күпере)

Бәрелгәч, бөҗәкләр тешләгәч беренче ярдәм күрсәтү кагыйдәләре белән таныштыру.

***Юлларда хәвер-хәтерсез йөрү тәртибе формалаштыру.***

Юлның элементлары белән таныштыру (машиналар өйри торган юл, җәяүлеләр юлы, тротуар), светофор, транспорт хәрәкәте белән.

Балалар бакчасына якын булган урамнар, балалар яши торган урам исемнәре белән таныштыру.

Юл йөрү кагыйдәләре белән, җәяүлеләр һәм велосипедистлар йөрү кагыйдәләре белән таныштыру.

Юл өйрү билгеләре белән таныштыру: “Балалар”, “Трамвай тукталышы”, “Автобус тукталышы”, “Җәяүле юлы”, “Беренче ярдәм күрсәтү ноктасы”, “Ашау урыны”, “Туктап тору урыны” һ.б.

***Тереклек эшчәнлек куркынычсызлыгы.***

Тереклек эшчәнлек куркынычсызлык нигезләрен ныгыту.

Төрле ел фасыллары вакытында уйнау кагыйдәләрен формалаштыру.

Көнкүрештә куркынычлык чыганаклары турында белемнәрен тулыландыру.

Янгыннар һәм янгын сүндерүчеләрнең эшләре турында күзаллауларын аныклау. МЧС службасаның эше белән таныштыру.

Өлкәннәргә ярдәм артыннан мөрәҗәгать итәргә өйрәтү.

**<u>Танып белү белем бирү өлкәсе</u>**

Балаларның танып белүен үстерүгә юнәлтелгән максатларын тормышка ашыру һәм интелектуаль үсү өчен түбәндәге мәсьәләләрне чишәргә түбәндәге бурычлар ярдәмендә чишә:

- танып-белү-тикшеренү һәм продуктив эшчәнлекләрен үстерү;
- сенсорик тәрбия;
- гади математик күзаллауларны формалаштыру;
- бербөтен дөнья картинасын, балаларның дөньяга карашын киңәйтүне;

***Сенсорик тәрбия***

Балаларны төрле билгеләренә, үзенчәлекләренә (төсе, формасы, зурлыгы, урнаштырылуы, аваз югарылыгы һ.б.) карап предметларны танырга, бер-берсе белән чагыштырырга өйрәтү. Әйтелгән билгесе буенча, предметларны парлау яисә башка предметлар арасыннан аерып төркемли белү күнекмәләре формалаштыру.

Балаларны спектр төсләре: кызыл, куе сары, сары, яшел, сыек зәңгәр, шәмәхә (хроматик төсләр) һәм ак, сары, кара (ахроматик төсләр) белән таныштыруны дәвам итү. Төсләрне яктылыгы, куелыгы буенча танырга, атый белергә өйрәтү. Спектрдагы төсләрнең урнашу үзенчәлеген аңлату.

Төрле геометрик фигуралар белән таныштыру эшен дәвам итү. Төрле формадагы предметларны өйрәнүне дәвам итү: иң зур өлешен,- зурлыгы буенча чагыштырып, калган ваграк кисәкләрен аерып әйтә белүләренә ирешү. Предметларны өйрәнү, тикшереп карау вакытында кулларны предмет буенча хәрәкәт иттерү. Күз үлчәмен камилләштерү. Предметларны һәм аларның өлешләрен зурлыклары, формалары, төсләре буенча чагыштыру күнекмәләрен үстерүне дәвам итү.

***Танып- белү- тикшеренү һәм продуктив эшчәнлекләрен үстерү;***

Балалар төзегән корылма һәм конструкцияләр һәм әйләнә тирәләрендә күрә торган корылмалар ( өйләр, ишегалдындагы спорт һәм уен җиһазлары һ.б.) арасында бәйләнеш урнаштыра белү.

Конструкцияләрнең төп өлешләрен һәм характерлы детальләрен күрсәтә белергә өйрәтү.

Балаларда күмәк эшләү, эшләрен уртак ниятләре белән яраштырып берләштерү, кемнең нәрсә эшләячәген уртак фикергә килеп хәл итү күнекмәләрен үстерү.

Мөстәкыйльлек, иҗади эш, инициатива, дустанә мөнәсәбәтләрне хуплау.

Тәрбияче эшләгән әйбер һәм корылмаларны анализларга, кисәкләрен аерып күрсәтергә, аларның кулланышын ачыкларга, анализлау нигезендә конструктив чишелешләр табарга һәм үзе төзеячәк корылманы эшләү этапларын планлаштырырга булышу.

Төрле зурлыктагы һәм формадагы пластиналар, борыслар, цилиндрлар, конуслар һ.б. белән таныштыру. Бер детальне икенчесе белән алмаштырырга өйрәтү.

Бер үк объектның зурлыгы һәм конструкциясе буенча төрле корылмалар төзү күнекмәләре формалаштыру.

Рәсемгә карап төзергә, төзелеш өчен кирәкле төзү материалларын мөстәкыйль сайларга өйрәтү.

**Проект эшчәнлеге**

Тикшеренү, иҗади, норматив проектлары тормышка ашырыр өчен төрле шартлар тудыру.

Тикшеренү проект эшчәнлеген үстерү, аларның презентацияләрен оештыру. Авторлы проектлар турында күзаллауларын формалаштыру.

Иҗади проектларны тормышка ашырыр өчен шартлар тудыру.

Норматив проектларны үстерүдә булышлык итү.

**Иң гади математик күзаллаулар формалаштыру**

***Сан һәм санау***

Билгеләре, үзенчәлекләре (төсләре, формасы, зурлыгы, материалы) төрле булган предметларны төркемләргә өйрәтү.

Предметларның ике төркемен санал чагыштырырга (күбрәк, азрак, бертигез) өйрәтү эшен дәвам итү. Күплекнең өлештән, кисәктән зуррак булуын аңлату. Күплекне кисәкләргә бүлү һәм аларны яңадан кушу.

10 га кадәр санарга өйрәтү; 5 тән 10 га кадәр булган саннарның барлыкка килүе (күрсәтмә материаллар нигезендә) белән таныштыру.

10 эчендә янәшә торган саннарны чагыштыру (күплекне чагыштырып карау нигезендә). Азрак булган төркемгә бер предметны өстән һәм күбрәк булган төркемнән бер дредметны алып тигез сан ясау. («7 8 дән кимрәк, әгәр 7 гә бер предметны өстәсәк, тигезләшә, 8 әр була», «8 7 дән күбрәк, әгәр 8 предметтан берсен алсак, тигезләшә, 7 шәр кала»).

Үрнәк яки бирелгән сан (10 эчендә) буенча зуррак төркемнән предметларны санап алу.

Капшап карап предметларны санау, ишетелгән авазларны, хәрәкәтләрне һәм бирелгән саннарны (10 эчендә) санау.

10 эчендә тәртип саны белән таныштыру, «Ничә?», «Ничәнче?» сорауларын аера һәм еларга дөрес җавап бирергә өйрәтү.

Тигезлек турында күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү; бирелгән саннар буенча тигез төркемнәр төзергә өйрәтү; санап һәм төркемнәрне чагыштырып саннарның тигез булуын билгеләү (монда 5 әтәч, 5 машина, 5 курчак — барлык уенчыклар бишәр).

Предметларның зурлыгына, формасына, кайда урнашуына, аларны санауның юнәлешенә (уңнан сулга таба, сулдан уңга, теләсә кайсы предметтан башлап) карап кына саннарның суммасы үзгәрмәгәнлеген төшендерү.

5 эчендәге саннарның төзелеше белән таныштыру (конкрет материалда); 5 — бу бер, бер, бер, бер һәм тагын бер.

Предметны (кәгазь битен, тасманы, түгәрәкне, квадратны һ.б.) берничә тигез кисәккә (ике, дүрт) бүлеп булуын төшендерү.

Бүлүдән барлыкка килгән өлешләрне әйтә белергә, бөтенне һәм өлешләрне чагыштыра, бөтен предметның үзенең һәр өлешеннән зуррак, ә өлешнең бөтеннән кимрәк булуын аңларга өйрәтү.

***Зурлык***

Төрле озынлыктагы, киңлектәге, биеклектәге предметларны үсә яки кими бару тәртибендә урнаштырырга өйрәтү. Предметларның урнашу тәртибен билгеләргә һәм аларның үлчәмнәре буенча чагыштырырга өйрәтү («Ал тасма — *иң киң,* шәмәхәсе— *бераз таррак,* кызылы — *тагы да таррак,* әмма ул *сарыдан киңрәк»* һ.б.)

Чагыштыру өчен алынган предметларның берсенең шартлы үлчәме ярдәмендә, ике предметны зурлыклары (озынлыгы, киңлеге, биеклеге) буенча чагыштырырга өйрәтү.

Предметларның зурлыгын (озынрак — кыскарак, биегрәк — тәбәнәгрәк, киңрәк — таррак) куз күләме белән билгеләргә өйрәтү.

***Форма***

Түгәрәк һәм турыпочмаклыкны чагыштыру нигезендә, балаларны *овал* белән таныштыру.

Дүртпочмак турында аңлату: квадрат һәм турыпочмаклыкның *дүртпочмак* төрләре икәнлеген төшендерү.

Формалары буенча таныш предметларны чагыштыру, якын тирәдә бертөрле һәм төрле формалы предметларны танып белергә өйрәтү (китап, картина, өстәл өсте — турыпочмаклы; поднос, кыяр — овал; тәлинкә, сәгать, кәстрүл капкачы — түгәрәк һ.б.).

***Тирә-юньдә ориентлашу***

Балаларның тирә-юньдә ориентлаша белүләрен ныгыту *(сулда, уңда, өстә, аста, алда, алдында, артында, арасында, янәшә).*

Үзенең яки башка предметның торышына карап, теге яки бу предметның урынын билгеләү («Курчакның *уң ягында* куян, ә *сул ягында* аю утыра; *артта* — туп, *алда* — машина»). Бирелгән

юнәлештә хәрәкәт итә белү, сигнал буенча һәм маршрут күрсәткечләренә (уклар) карап юнәлешне үзгәртә белү күнекмәләре бирү *(алга, артка, сулга, уңга* һ.б.); әйләнә-тирәдәге предметларга яисә кешеләргә карап үз торышыңны билгеләү: «Мин Әминә белән Асия *арасында* басып торам, Галия *алдында,* Самат *каршында,* мәктәп *янында** һ.б.

Балаларны кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтү *(сулда, уңда, өстә, аста, уртада ).*

***Вакытта ориентлашу***

Иртә, көндез, кич, төннең тулы бер тәүлек тәшкил итүе турында күзаллау бирү. Атна көннәрен эзлекле рәвештә исемнәре белән атап чыгарга, *бүген* нинди көн, *кичә* нинди көн иде, *иртәгә* нинди көн икәнен әйтергә өйрәтү.

***Предметлы тирәлек һәм иҗтимагый тормыш күренешләре.***

Балаларның сөйләмендә төрле предметларның атамаларын актив кулланышка кертү. Таныш булмаган предметларның файдалану үзенчәлекләре белән таныштыру.

Материалларның сыйфатын мөстәкыйль билгели белү күнекмәләрен үстерү. Предметларның сыйфатын, үзенчәлеген (өслекнең төзелеше: температурасы; катылыгы — йомшаклыгы; уалучанлыгы — ныклыгы; ялтыравы; яңгырашы һ.б.) тасвирлый белү күнекмәләре бирү.

Предметларның төсен, зурлыгын, формасын, авырлыгын билгели белергә өйрәтү эшен дәвам итү.

Предметларны чагыштырырга (төсе, кулланышы, нинди материалдан эшләнгән булуы, формасы буенча) һәм төркемләргә (савыт-саба — пыяла, фарфор, пластмасса) өйрәтү.

һәрбер әйбернең кешеләр кулы белән эшләнүен («Өстәл ничек эшләнә?», «Китап ничек басылып чыга?» һ.б.); кулланырга уңайлы булсын өчен, кешеләрнең күп кенә предметларны яши-яши камилләштерә баруын (каз каурые — каләм — авторучка) аңлату. Предметларның тарихы (үткәне, бүгенгесе) турында сөйләүне дәвам итү.

Көнкүрештә кеше хезмәтен җиңеләйтүче предметлар турында (вентилятор, бра, тузан суырткыч, суыткыч һ.б.) күзаллау формалаштыру. Әйберләрнең ныклыгы, чыдамлыгы, озак кулланышлы булуы аның нинди материалдан эшләнүенә бәйле икәнен төшендерү (яхшы сыйфатлы материалдан эшләнгән әйбер нык була, озакка чыдый).

Балаларның өлкәннәр хезмәте, аларның һөнәрләре турында белемнәрен киңәйтү. Аларны төзүчеләр (ташчы, буяучы һ.б.), авыл эшчәннәре (игенче, сыер савучы, терлекче һ.б.), транспорт (шофер, трамвай йөртүче, машинист һ.б.), элемтә (хат ташучы), тегү сәнәгате (кисүче, тегүче) хезмәткәрләренең хезмәте белән таныштыру. Алар хезмәтенең мөһимлеге, әһәмиятлелеге турында сөйләү. Хезмәт кешесенә хөрмәт тәрбияләү.

Уку йортлары турында күзаллауларын киңәйтү(балалар бакчасы, мәктәп, колледж, югары белем бирү уку йорты), эшчәнлек сфералары турында (фән, иҗат, җитештерү, авыл җирлеге)

Культура күренешләре белән таныштыруны дәвам итү (цирк, библиотека, музей һ.б.), телевидение, музейлар, театр, цирк, кино, китапханәләр турында белемнәрен киңәйтү һәм аларны барып күрергә теләк тудыру.

Бюджет, акча һәм аның функциональ яклары белән таныштыру.

Кешелек тарихы белән иҗади сәнгать әсәрләре аша таныштыру(рәсем сәнгате, скульптура, миф, халык легендалары)

Иҗади һөнәрләр (рәссам, композитор, музыкант, актер, балет артисты һ.б.), аларның әһәмияте, үзенчәлекләре турында күзаллауларын киңәйтү. Балаларны «халык сәнгате», «халык сәнгатенең төрләре һәм жанрлары» төшенчәләре белән-таныштыру.

**Әйләнә-тирә, табигать дөньясы белән таныштыру.**

Балалар белән табигать күренешләрен күзәтеп, алар арасындагы үзара бәйләнеш булуы турында нәтиҗә чыгарырга өйрәтү. Үсемлекләр үсүе һәм хайваннарның яшәү шартлары турындагы белемнәрен тирәнәйтү, кеше — табигатьнең бер өлеше икәнлеген төшендерү. Табигатькә зыян китермәү кагыйдәләрен өйрәтү.

Үсемлекләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, ныгыту (болын, кыр, урман үсемлекләре; бүлмә гөлләре; урман, бакча җиләкләре һ.б.). Бүлмә гөлләре үрчетүнең кайбер вегетатив ысуллары белән таныштыру: ботактан, яфрактан, мыекчадан. Үсемлекләр һәм аларның яшәеше өчен мөһим роль уйнаган табигать шартлары арасындагы бәйләнешне аңлый, күрә белергә; үсемлекләрдәге үзгәрешләрнең сәбәпләрен аңларга, төшенергә ярдәм итү (яфраклары кипкән — су җитми; акрын үсә — туклыклы матдәләр җитешми һ.б.).

Кыргый хайваннар һәм аларның гадәтләре белән таныштыруны дәвам итү. Туган якта, башка илләрдә яшәүче кайбер җәнлекләрне танып әйтергә өйрәтү.

Кышлаучы һәм күчмә кошлар турында күзаллауларын формалаштыру. Кышлаучы берничә кошны: чыпчык, чәүкә, кызылтүш, песнәк һ.б. кошларны тышкы билгеләренә карап танырга өйрәтү.

Кышлаучы кошларга, кыргый җәнлекләргә кешеләрнең күрсәткән игелекле гамәлләре турында сөйләү.

Йорт хайваннары турындагы белемнәрен системалаштыру. Йорт кошлары, аларның үзенчәлекле тышкы билгеләре, гадәтләре, кешеләрнең аларны ничек караулары белән таныштыруны дәвам итү.

Тере почмактагы тереклек ияләре (балыклар, кошлар, әрләннәр һ.б.) турындагы күзаллауларын киңәйтү, аларны карау үзенчәлекләрен белү; аларга карата җаваплылык хисләре тәрбияләү.

Ел фасыллары, тәүлек бүленеше турындагы күзаллауларын системалаштыру, гомумиләштерү.

Гади генә тәҗрибәләр ясап, балаларның экологик фикерләү сәләтен үстерү.

Балаларның космос, ай, кояш, йолдызлар һ.б. турындагы сорауларына алар аңларлык итеп җавап бирү. Кызыксынуларына карап, балаларның табигать турындагы белемнәрен киңәйтү.

Әйләнә-тирә дөньяга эстетик мөнәсәбәт формалаштыру. Балаларның табигатьтән алган тәэсирле хисләрен, фикерләрен рәсемдә, кисеп ябыштыру һәм әвәләү дәресләрендә сурәтләү омтылышларын хуплау. Төрле чыганаклар аша (телетапшырулар карау, экскурсияләр, сәяхәтләр һ.б.) алган белемнәрен башкалар белән уртаклашасы килү теләге уяту.

Кояш, һава, су кебек табигый факторлар ярдәмендә балаларның сәламәтлеген ныгыту. Сәламәт яшәү рәвеше, тормыш куркынычсызлыгы нигезләре турында сөйләү.

**Танып белү үсеше буенча перспектив план**

| **Ай** | **ФЭМП** | **Дөньяныңербөтенлеген формалаштыру: Экология Әйләнә - тирә** | **Төзү** |
|---|---|---|---|
| **Сентябрь** | 1.Сан һәм санау. (17)<br>1. Сан һәм санау. (18)<br>2. Сан һәм санау. (20)<br>2. Сан һәм санау. (21)<br>3. Сан һәм санау. (23)<br>3. Сан һәм санау (24)<br>4. Сан һәм санау. ( 25)<br>4. Сан һәм санау. (26) | 1. Табигать һәм кеше ( 31бит)<br>2. Көзге байлык. (41)<br>3.Минем йортым, минем гаиләм. (47)<br>4. Балаларның хаклыклары һәм бурычлары ( 56) | 1. Табигый материалдан өй. (29бит)<br>2. Оригами «Тюльпаннар» (39)<br>3. Төзү материалларыннан биналар. (49)<br>4. Оригами «Бака» ( 59) |
| **Октябрь** | 1. Сан һәм санау ( 27)<br>1. Сан һәм санау. (31)<br>2. Сан һәм санау (32)<br>2. Сан һәм санау. (34)<br>3. Сан һәм санау (36)<br>3. Сан һәм санау (38)<br>4. Сан һәм санау. ( 41)<br>4. Сан һәм санау. (44) | 1. Мәктәпкә сәяхәт.(66)<br>2. Транспорт. (76)<br>3. Тиредән ясалган әйберләр күргәзмәсендә. ( 84)<br>4. Бакча ашханәсенә сәяхәт.(97) | 1. Табигый материалдан сал. (68)<br>2. Оригами «Чеби» (77)<br>3. Табигый материалдан көймә. (87)<br>4. Оригами «Көймә» (100) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Ноябрь** | 1. Сан һәм санау. (46)<br>1. Сан һәм санау . (48)<br>2. Сан һәм санау.. (51)<br>2.Санау һәи предметларның санын чагыштыру. (54)<br>3. Математика уеннары. (55)<br>3. Предметларның санын чагыштыру. ( 58)<br>4. Предметларны санау. (61)<br>4. 10 га кадәр сан. (64) | 1.Безнең планета. Җир планетасы куркыныч астында. (110)<br>2. Африка буйлап сәяхәт. (124)<br>3. Алты аяклы кечкенәләр.(135)<br>4. Көз килде, сигез төрле һава торышы алып килде. (147) | 1.Ракушкалардан җилкән. (стр. 112)<br>2.Пластмасс калаклардан курчаклар. (122)<br>3.Каен тузыннан машина. (132)<br>4. Оригами «Балык» (148) |
| **Декабрь** | 1.Төрле билгеләре буенча предметлпрны чагыштыру. (67)<br>1. Санау. (69) .<br>2. Санау. Геометрик фигуралар<br>ны чагыштыру. (71).<br>2. Логик фикерләүне һәм игъти<br>барлылыкны үстерү.(73)<br>3.Предметларның санын чагыш<br>тыру.(76)<br>3. Логики фикерләүне үстерү. (77)<br>4. Санау. (80)<br>4. Санау. (83) | 1.Туган һәм туганлык. (154)<br>2.Җир асты байлыклары. (168)<br>3. Кайчы агачтан бала. (177)<br>4.Чыршы кайдан кунакка килгән. (185) | 1.Төзү материалларыннан машина. (157)<br>2. Кар бабай. (166)<br>3. Табигый материалдан вертолет. (175)<br>4. Яңа ел чыршысы. (184) |
| **Январь** | 1. Санау һәм саннарны чагышты<br>ру. (85)<br>1. Сан һәм санау. (88)<br>2. Санау. (90)<br>2. Санау. (93)<br>3. Рәт саны. (95)<br>3. Кызыклы мәсьәләләр. (96)<br>4. Санау. (98)<br>4. Чагыштыру. (100) | 1. Яшь эколог. (195)<br>2. Юл билгеләре белән танышу. (204)<br>3. Су транспорты. (214)<br>4. Кышлаучы кошлар. (216) | 1. Табигый материалдан вертолет. (193)<br>2. Фонариклар. ( 207)<br>3. Табигый материалдан фигуралар. (215)<br>4.Оригами «Камка» (225) |
| **Февраль** | 1. Санау.(101)<br>1. Математик мәсьәләләр. (103)<br>2. Санау. (106)<br>2.Әйләнә-тирәдә ориентирлашу. (109)<br>3 .Логик фикерләүне үстерү. (111)<br>3. Санау. (114)<br>4. Мәсьәләләр төзү һәм чишү.(116)<br>4.Мәсьәләләр чишү. (118) | 1.Таныш булыгыз: минем дустым – компьютер. (232)<br>2. Поляр районнарның җәнлекләре. (246)<br>3.Безнең яраткан армиябез. (252)<br>4. Без барыбыз да – җирдә яшәүчеләр. (266) | 1. Космонавт ракета янында. (234)<br>2. Оригами «Күбәләк» (244)<br>3. Вертолет ракушкалар<br>дан. (254)<br>4. Открытка «Яңа чык кан чеби» (265) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Март** | 1. Рәсемнәрдә һәм шигырьләрдә мәсьәләләр. (120)<br>1.10арасында сан составы. (123)<br>2. Мәсьәләләр чишү. (126)<br>2. Сан составы турында белемнәрне ныгыту. (128)<br>3.Мәсьәлә төзү. (130)<br>3. Логик мәсьәләләр. (132)<br>4. Санау һәм саннарны чагыштыру.<br>(134)<br>4. Чагыштыру( 136) | 1.Әбием сандыгы. (272)<br>2.Урман һәм кеше. (285)<br>3. Милли бәйрәм - Масленица. ( 299)<br>4. Мәскәү – Россиянең башкаласы. (300) | 1.Робот Роб имән чикләвегеннән. (274)<br>2.Бөгәрләнгән кәгазьдән чеби. (284)<br>3. Төзү материалларыннан биналар. (294)<br>4. Оригами «Төлке» (304) |
| **Апрель** | 1. Озынлык буенча чагыштыру. (138)<br>1. Озынлык һәм киңлек буенча чагыштыру. (140)<br>2. Мерка белән күләмне һәм озынлыкны үлчәү. (143)<br>2. Форма турында белемнәрне ныгыту.(145)<br>3. Форма турында белемнәрне ныгыту. (147)<br>3. Форма турында белемнәрне ныгыту. (149)<br>4. Логиканы үстерү буенча биремнәр. (151)<br>4. Предметларны формалары буенча аеру. (153) | 1.Юл йөрү һәм иминлек кагыйдәләре (312)<br>2. Космонавт буласым килә. (322)<br>3. Җир бәйрәме. (336)<br>4. Җир – безнең йортыбыз. (343) | 1.Селкенгенч ат. (316)<br>2. Оригами «Эт баласы» (324)<br>3. Аю фигуркасы. (334)<br>4. Кәгазьдән йөрәк. (345) |
| **Май** | 1. Форма турында белемнәрне ныгыту.(155)<br>1.Форма турында белемнәрне ныгыту.(361)<br>2.Әйләнә - тирәдә ориентлашу. (367)<br>2. Әйләнә - тирәдә ориентлашу. (372)<br>3. Әйләнә - тирәдә ориентлашу. ( 379)<br>3.Вакытта ориетлашу. (386)<br>4. Вакытта ориетлашу.(393)<br>4. Вакытта ориетлашу (398) | 1.Безнең армия. Җиңү көне. (353)<br>2. Телевизор безнең өйдә. (365)<br>3. Сәламәт ашамлык. (382)<br>4. Исәнме, матур җәй. (396) | 1. Кәгазьдән бака. (355)<br>2. Оригами «Күбәләк» (367)<br>3. Шәһәрдә күперләр. (379)<br>4. Оригами «Песи баласы» (393) |

**<u>Сөйләм үстерү белем бирү өлкәсе</u>**

Аралашу чарасы буларак, балаларның сөйләмен үстерүне дәвам итү. Әйләнә-тирә дөньяның күптөрлелеге турында күзаллауларын киңәйтү. Карау өчен балаларга халыкның кул хезмәте эшләнмәләре, мини-коллекцияләр (открыткалар, маркалар, тәңкәләр, бертөрле материалдан эшләнгән уенчыклар тупламасы һ.б.), иллюстрацияле китаплар (төрле рәссамнар кулы белән бизәлгән таныш әкиятләр һ.б.), башкаланың, туган якның истәлекле урыннары сурәтләнгән

открыткалар, картиналар репродукцияләре, карта, глобус һ.б. тәкъдим итү (программаның алдагы бүлекләрендә күрсәтелгән тәкъдимнәрне исәпкә алып).

Карау өчен бирелгән предметлар (картина, альбом, буклет) турында мөстәкыйль рәвештә сөйлисе килү теләген хуплау, хикәя төзеп сөйләүгә булышлык итү, теге яки бу әйбер белән кызыксынган балалар өчен кабатлап сөйләү мөмкинлеге тудыру. Баланың педагог һәм башка балалар белән төрле хәбәрләр уртаклашасы килү теләген хуплау, алынган мәгълүматның чыганагын (телетапшыру, якын кешенең сөйләве, күргәзмәдә, балалар спектаклендә булу һ.б.) ачыклау.

Көндәлек тормышта, уен вакытында башкаларга карата ягымлы мөгамәлә булдыру (гафу үтенү, рәхмәт әйтү, мактау һ.б.). Сөйләм чаралары (ышандыру, аңлату, исбатлау) ярдәмендә бәхәсле сорауларны, конфликтларны уңай хәл итәргә өйрәтү.

***Сүз байлыгын үстерү***

Тирә-юнь турындагы белемнәрен киңәйтү исәбенә, балаларның сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру.

Көнкүреш предметларын белдерүче, өлкәннәрнең һөнәрләрен аңлатучы, үсемлекләр һәм хайваннар, кошлар, табигать күренешләре атамалары; предметларның төрле билгеләрен (төсен, формасын һ.б.), кешеләрнең характерын белдерүче сыйфатлар; кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен, хезмәткә карата мөнәсәбәтләрен» кәефләрен һ.б. белдерүче рәвешләр; кешеләрнең эш-гамәлләрен,

хезмәт эшчәнлеген белдерә торган фигыльләр исәбенә балаларның сүзлеген баету һәм кулланышка кертү.

Исемнәрне сыйфатлар белән бәйләргә өйрәтү (ак — кар, шикәр; матур — күлмәк, чәчәк); мәгънәдәш сүзләр (шаян — шук), капма-каршы мәгънәле сүзләр (каты — йомшак, биек — тәбәнәк, якты — караңгы) куллану күнекмәләре бирү.

***Авазларны дөрес әйтергә өйрәтү***

Авазларны дөрес, ачык итеп әйтергә, сүзләрне үз мәгънәсендә кулланырга өйрәтү эшен дәвам итү. Әйтелеше һәм яңгырашы буенча охшаш тартык авазларны ишетеп аера һәм ачык итеп әйтә белү күнекмәләре бирү: *с—з, с—ц, ш*—ж, ч—ц, *с—ш, ж—з, л—р.*

Фонематик ишетү сәләтләрен үстерү. Сүздә авазның урынын билгеләргә (башында, уртасында, ахырында) өйрәтү.

Сәнгатьле сөйләм өстендә эшләү.

***Сөйләмнең грамматик төзелеше***

Җөмләдә сүзләрне яраштыра белү күнекмәләре бирү эшен дәвам итү: исемнәрне саннар белән (биш алма, өч малай), сыйфатларны исемнәр белән (яшел чиләк, җылы кояш) яраштырып сөйләргә өйрәтү. Сүздә дөрес куелмаган басымны, тартык авазларны чиратлаштырудагы хаталарны әйтә белергә өйрәтү.

Сөйләшкәндә, хикәяләр сөйләгәндә, әңгәмәләрдә сүз ясагыч кушымчалардан файдаланырга өйрәтү (авылдаш, игенче, ташлык, тозсыз, яшьтәш, сулы Һ.б.).

Тамырдаш сүзләр ясау күнекмәләре бирү: бал — баллы — балсыз, аш — аша — ашлык, эш — эшчән — эшсез һ.б.

Берлек сандагы сүзләрне күплек формасына әйләндерә белергә өйрәтү эшен дәвам итү (курчак — курчаклар, китап — китаплар, гөл — гөлләр, апа — апалар); боерык фигыль ясый белү һәм сыйфатларның чагыштыру дәрәҗәсен төзү күнекмәләре булдыру.

Сөйләмдә гади, һәм кушма җөмләләрне куллану күнекмәләрен ныгыту. Туры һәм кыек сөйләмне кулланырга өйрәтү эшен камилләштерү.

***Бәйләнешле сөйләм***

Балаларның диалогик һәм монологик сөйләмен үстерү юнәлешендә эшләү: иптәшләре белән үзара тыныч, ягымлы итеп сөйләшә белергә, башкалар сөйләгәнне игътибар белән тыңларга өйрәтү. Сораулар бирергә, тәрбияче һәм балалар биргән сорауларга төгәл, һәркем ишетерлек һәм аңларлык итеп җавап бирергә күнектерү.

Күләме зур булмаган әдәби әсәрләрне (әкият, хикәяләр), тәрбияче сорауларыннан башка, бәйләнешле, әзлекле һәм сәнгатьле итеп сөйләү күнекмәләре бирү. Персонажларны кичерешләренә бәйле рәвештә, интонацияне үзгәртеп, кирәкле урында пауза ясап сөйләргә өйрәтү.

Балаларны, билгеле бер әйбер турында яки рәсемнәргә карап, тәрбияче үрнәгендә яки бирелгән план нигезендә кечкенә хикәяләр төзеп сөйләргә өйрәтү. Үзенә таныш вакыйгалар

турында тулы җөмләләр белән сөйли белергә, тәрбияче тәкъдим иткән тема буенча зур булмаган хикәяләр төзеп сөйләргә өйрәтү.

**Матур әдәбият әсәрләре белән кызыксынуын үстерү.**

Балаларның матур әдәбият әсәрләре белән кызыксынуын үстерү. Игътибар белән әкиятләр, хикәяләр, шигырьләр тыңларга өйрәтү; санамышлар, тизәйткечләр, табышмаклар ятлату. Зур әсәрләр укуга (бүлекләре) кызыксыну тудыру. Төрле алымнар һәм махсус оештырылган педагогик ситуацияләр ярдәмендә әдәби әсәрләргә эмоциональ мөнәсәбәт формалаштыруга булышлык итү. Әсәр геройларының хәленә керә белә торган китап укучы тәрбияләү. Әдәби персонажның кылган гамәлләре турында фикерләрен сөйли белергә өйрәтү. Әсәр геройларының гамәлләрендәге яшерен мотивларны аңларга булышу.

Әкият, хикәя, шигырьләрнең төп жанр үзенчәлекләрен аңлату. Матур әдәбият әсәрләрен күңелең белән тою, сиземләү хисләре булдыру; әсәрләрнең иң ошаган урыннарын кабатлап уку. Шигырьләрне яттан сәнгатьле итеп сөйләү күнекмәләре бирү. Текстны рольләргә бүлеп уку, әсәрләрне сәхнәләштерү күнекмәләре булдыруга булышлык итү.

Китаплар белән таныштыру эшен дәвам итү. Балаларның игътибарын китапларның бизәлешенә, иллюстрацияләренә юнәлтү. Үзеңнең яраткан китапларың турында башкаларга сөйли белергә өйрәтү.

**Сөйләм үстерү буенча перспектив план**

| **Ай** | **Сөйләм үстерү** | **Грамотага өйрәтү** |
|---|---|---|
| **Сентябрь** | 1. “Исәнме, мәктәп!”<br>2. «Балалар мәктәпкә баралар» картинасы буенча сөйләү. 46<br>3”Сара мәктәпкә бара” хикәя уку.<br>4. В.Осеева “Тылсымлы сүз” | 1. А авазы, А, а хәрефе. 12<br>2. У авазы, у хәрефе.15<br>3. О авазы, О хәрефе.19<br>4.М авазы, М хәрефе. 22 |
| **Октябрь** | 1. «Минем туган җирем” хикәя төзү.<br>2. Абдулла Алиш иҗаты белән танышу.<br>3. Картина – пейзаж буенча сөйләү(күз).<br>4. Әкиятләр турында әңгәмә. | 1. С авазы, С хәрефе. 26<br>2. Х авазы, Х хәрефе. 30<br>3. Ш авазы, Ш хәрефе. 34<br>4. |
| **Ноябрь** | 1. “Минем гаилә”. Иҗади хикәя төзү.<br>2. З.Туфайлова “Минем гайләм”<br>3. «Төлке балалары белән» картинасы буенча сөйләү.<br>4. Былина «Садко». | 1. Л авазы, Л хәрефе39<br>2. Өйрәнгәннәрне кабатлау. 42<br>3. Н авазы, Н хәрефе48<br>4. Р авазы, Р, р хәрефе. 53 |
| **Декабрь** | 1. Сүзле уен «Нидән нәрсә ясалган?»<br>2. И. Суриков әсәрләре белән танышу.<br>3. Н. П. Крымовның «Кышкы кич» картинасы буенча сөйләү.<br>4. Чагыштырып сөйләү «Кышкы кич» | 1. Р һәм Л авазларын чагыштыру . 57<br>2 .К авазы, К хәрефе.62<br>3. К авазы, К хәрефен ныгыту. Җөмлә өстендә эш. 69<br>4. П авазы, П хәрефе76 |
| **Январь** | 1.С. Маршакның «Яшь ай эри…» шигырен өйрәнү.<br>2. Кышкы уеннар.<br>3. «Буталчык» картинасын карау .<br>4. Е. Чарушинның «Аю» әсәрен сөйләү. | 1. Т авазы, Т хәрефе. 82<br>2. И авазы, И хәрефе.88<br>3. З һәм С авазларын чагыштыру. 94<br>4. В авазы, В хәрефе.100 |

| | | |
|---|---|---|
| **Февраль** | 1. «Куркуның күзләре зур» әкиятен сөйләү. 241<br>2. Минем яраткан уенчыгым.<br>3.В. Бианки хикәясе «Кирәк-яраклар».<br>4. Әңгәмә «Кечкенәләрне без ничек кайгыртабыз» . | 1. Ж авазы, Ж хәрефе.106<br>2. Б авазы, Б хәрефе. Б һәм П авазларын чагыштыру112<br>3. Г авазы, Г хәрефе. К һәм Г авазларын чагыштыру. 119<br>4. Д һәм Т авазларын чагыштыру. Орфография һәм орфоэпия. 24 |
| **Март** | 1. Үзең уйлап сөйләү «Минем әни» .<br>2. Яхшы эшләр.<br>3. В. М. Васнецовның «Батырлар» картинасы буенча сөйләү.<br>4.М. Пришвина «Алтын болын» хикәяләре. | 1. И һәм Й авазларын чагыштыру. 129<br>2. Ь сүз уртасында нечкәлек билгесе. 133<br>3. Е авазы, Е, е хәрефе. 138<br>4. Я авазы, Я хәрефе. 144 |
| **Апрель** | 1. Картина буенча сөйләү.<br>2. Әкият уйлап чыгару.<br>3. Хикәя төзү.<br>4. Әкият төзү. | 1. Ю авазы, Ю хәрефе.150<br>2. Ё авазы, Ё, ё хәрефе. 154<br>3. Ц авазы, Ц хәрефе.160<br>4. Ц һәм Ч авазларын чагыштыру. 165 |
| **Май** | 1. Яз турында әйтемнәр һәм такмаклар.<br>2. А. Блокның «Болында» шигыре.<br>3. «Иртә яз» картинасы буенча әңгәмә.<br>4. Сүзләр белән уен. | 1. Ф авазы, Ф,ф хәрефе. 169<br>2. Ъ – аерымлык, катылык билгесе, Ь- нечкәлек билгесе . 174<br>3. Үткәннәрне кабатлау.<br>4. Йомгаклау шөгыле. |

**Матур әдәбият уку буенча переспектив план**

| Ай | ООБЭ | Берләшкән эшчәнлек |
|---|---|---|
| **Сентябрь** | 1. А.С. Пушкинның «Евгений Онегин» поэмасы белән танышу. 28<br>2. Нанай халык әкияте «Айога», уку һәм сөйләү. 38<br>3. Рус халык әкияте «Төлке һәм бүре»..47<br>4. Былина «Илья Муромец һәм Соловей - разбойник». 56 | **Русский фольклор**<br>***Песенки.*** «Лиса рожью шла...»; «Чигарики-чок-чигарок...»; «Зима пришла...»; «Идет матушка весна...»; «Когда солнышко взойдет, роса на землю падет...».<br>***Календарные обрядовые песни.*** «Коляда! Коляда! А бывает коляда...»; «Коляда, коляда, ты подай пирога...»; «Как пошла коляда...»; «Как на масляной неделе...»; «Тин-тин-ка...»; «Масленица, Масленица!».<br>***Прибаутки.***«Братцы, братцы!..»; «Федул, что губы надул?..»; «Ты пирог съел?»; «Где кисель — тут и сел»; «Глупый Иван...»; «Сбил-сколотил — вот колесо».<br>***Небылицы.*** «Богат Ермошка», «Вы послушайте, ребята».<br>***Сказки и былины.*** «Илья Муромец и Соловей-разбойник» (запись А. Гильфердинга, отрывок); «Василиса Прекрасная» (из сборника сказок А. Афанасьева); «Волк и лиса», обр. И. Соколова- |
| **Октябрь** | 1.К. Г. Паустовский «Җылы икмәк». 66<br>2. Н. Рубцовның «Куян турында» шигырен ятлау. 76<br>3. А. Купринның «Фил» хикәясен уку .84<br>4. В. Биянкиның«Аюлар су коена» хикәясен уку.108 | |

| | | |
|---|---|---|
| **Ноябрь** | 1. Д. Мамина – Сибирякның «Медведко» әсәре белән танышу. 110<br>2.Ш. Перроның «Кот в сапогах» әкияте. 120<br>3.М. Зощенконың «Бөек сәяхәтчеләр» хикәясе.130<br>4. В. Сутеевның «Палочка – выручалочка» әкиятен уку. 152 | Микитова; «Добрыня и Змей», пересказ Н. Колпаковой; «Снегурочка» (по народным сюжетам): «Садко» (запись П. Рыбникова, отрывок); «Семь Симеонов — семь работников», обр. И. Карнауховой; «Сынко-Филипко», пересказ Е. Поленовой: «Не плюй в колодец — пригодится воды напиться», обр. К. Ушинского.<br>**Фольклор народов мира**<br>***Песенки.*** «Перчатки», «Кораблик», пер с англ. С. Маршака; «Мы пошли по ельнику», пер. со швед. И. Токмаковой; «Что я видел», «Трое гуляк», пер. с франц. Н. Гернет и С. Гиппиус; «Ой, зачем ты, жаворонок...», укр., обр. Г. Литвака; «Улитка», молд., обр. И. Токмаковой.<br>***Сказки.*** Из сказок Ш. Перро (франц.): «Кот в сапогах», пер. Т. Габбе: «Айога», нанайск., обр. Д. Нагишкина; «Каждый свое получил», эстон., обр. М. Булатова; «Голубая птица», туркм., обр. А. |
| **Декабрь** | 1. К. Ушинскийның «Төлке һәм кәҗә» әкияте. 154<br>2. Е. Пермякның «Беренче балык» хикәясе. 172<br>3. Ю. Ковальның «Стожок» әсәре белән танышу. 173<br>4. «Кар кызы» әкияте.182 | |
| **Январь** | 1.Карлы кыш. 200<br>2.Э. Мошковскаяның «Кичкә кадәр йөгерде» шигыре.204<br>3. П. Ершовның «Конек - Горбунок» әсәре белән танышу. 214<br>4. Рус халык әкияте «Алтын кикрикле әтәч».223 | Александровой и М. Тvберовского; «Беляночка и Розочка», пер. с нем. Л. Кон; «Самый красивый наряд на свете», пер. с япон. В. Марковой.<br>**Произведения поэтов и писателей России**<br>***Поэзия.*** М. Волошин. «Осенью»; С. Городецкий. «Первый снег»; М. Лермонтов. «Горные вершины» (из Гёте); Ю. Владимиров. «Оркестр»; Г. Сапгир. «Считалки, скороговорки»; С. Есенин. «Пороша»; А. Пушкин. «Зима! Крестьянин, торжествуя...» (из романа «Евгений Онегин»), «Птичка»; П. Соловьева. «День и ночь»; Н. Рубцов. «Про зайца»; Э. Успенский. «Страшная история», «Память»; А. Блок. «На лугу»; С. Городецкий. «Весенняя песенка»; В. Жуковский. «Жаворонок» (в сокр.); Ф. Тютчев. «Весенние воды»; А. Фет. «Уж верба вся пушистая» (отрывок); Н. Заболоцкий. «На реке».<br>***Проза.*** А. Куприн. «Слон»; М. Зощенко. «Великие путешественники»; К. Коровин. «Белка» (в сокр.); С. Алексеев. «Первый ночной таран»; Н. Телешов. «Уха» (в сокр.); Е. Воробьев. «Обрывок провода»; Ю. Коваль. «Русачок-травник», «Стожок»; Е. Носов. «Как ворона на крыше заблудилась»; С. Романовский. «На танцах».<br>***Литературные сказки***. А. Пушкин. «Сказка о мертвой царевне и о се- ми богатырях»; А. Ремизов. «Хлебный голос», «Гуси-лебеди»; К. Паустовский. «Теплый хлеб»; В. Даль. «Старик-годовик»; П. Ершов. «Конек-Горбунок»; К. Ушинский. «Слепая лошадь»; К. Драгунская. «Лекарство от послушности»; И. Соколов-Микитов. «Соль земли»; Г. Скребицкий. «Всяк по-своему». |

<table>
<tr>
<td>Февраль</td>
<td>1.С.Есенинның «Каен» шигыре. 232<br>2. Х. К. Андерсенның «Гадкий утенок» әкиятен уку. 243<br>3. Н. Сладковның «Чыпчык язы» хикәяләре.261<br>4. Рус халык әкияте « Гүзәл Василиса» .263</td>
<td rowspan="3">Произведения поэтов и писателей разных стран<br>Поэзия. Л. Станчев. «Осенняя гамма», пер. с болг. И. Токмаковой; Б. Брехт. «Зимний разговор через форточку», пер. с нем. К. Орешина; Э. Лир. «Лимерики» («Жил-был старичок из Гонконга...», «Жил-был старичок из Винчестера...», «Жила на горе старушонка...», «Один старикашка с косою...»), пер. с англ. Г. Кружкова.<br>Литературные сказки. Х.-К. Андерсен. «Дюймовочка», «Гадкий утенок», пер. с дат. А. Ганзен; Ф. Зальтен. «Бемби», пер. с нем. Ю. Нагибина; А. Линдгрен. «Принцесса, не желающая играть в куклы», пер. со швед. Е. Соловьевой; С. Топелиус. «Три ржаных колоска», пер. со швед. А. Любарской.<br>Примерный список для заучивания наизусть (по выбору воспитателей)<br>Я. Аким. «Апрель»; П. Воронько. «Лучше нет родного края», пер. с укр. С. Маршака; Е. Благинина. «Шинель»; Н. Гернет и Д. Хармс. «Очень- очень вкусный пирог»; С. Есенин. «Береза»; С. Маршак. «Тает месяц молодой...»; Э. Мошковская. «Добежали до вечера»; В. Орлов. «Ты лети к нам, скворушка...»; А. Пушкин. «Уж небо осенью дышало...» (из «Евгения Онегина»); Н. Рубцов. «Про зайца»; И. Суриков. «Зима»; П. Соловьева. «Подснежник»; Ф. Тютчев. «Зима недаром злится» (по выбору воспитателя).<br>Для чтения в лицах<br>К. Аксаков. «Лизочек»; А. Фройденберг. «Великан и мышь», пер. с нем. Ю. Коринца; Д. Самойлов. «У Слоненка день рождения» (отрывки); Л. Левин. «Сундук»; С. Маршак. «Кошкин дом» (отрывки).<br>Дополнительная литература</td>
</tr>
<tr>
<td>Март</td>
<td>1. В. Дальнең «Старик - годовик» хикәясе. 272<br>2.Ф. Тютчевның «Кыш ачулана»<br>шигыре. 281<br>3. Х. К. Андерсенның «Дюймовоч<br>ка» әкияте. 290<br>4. Е. И. Чарушинның «Кабан» хикәясе.302</td>
</tr>
<tr>
<td>Апрель</td>
<td>1.Эдвард Лирның «Лимерики» шигыре. 312<br>2. Яз турында шигырьләр. 322<br>3. В. Бианкиның «Урман өйләре» хикәясе. 332<br>4.Бертуган Гриммнарның «Чүл мәкле ботка» әкияте. 343</td>
</tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| Май | 1. С. Алексеевның «Беренче төнге таран» хикәсе. 353<br>2. А. С. Пушкин әкитләре. 373<br>3. Рус халык әкияте « Аленушка апасы һәм Иванушка энесе»<br>С.Аксаковның «Ал чәчәк» экия-<br>тен сөйләү . 379<br>4. Табышмаклар, тизәйткечләр һәм санамышлар. 390 | ***Сказки***. «Белая уточка», рус., из сборника сказок А. Афанасьева; «Мальчик с пальчик», из сказок Ш. Перро, пер. с фран. Б. Дехтерева.<br>***Поэзия.*** «Вот пришло и лето красное...», рус.нар. песенка; А. Блок. «На лугу»; Н. Некрасов. «Перед дождем» (в сокр.); А. Пушкин. «За весной, красой природы...» (из поэмы «Цыганы»); А. Фет. «Что за вечер...» (в сокр.); С. Черный. «Перед сном», «Волшебник»; Э. Мошковская. «Хитрые старушки», «Какие бывают подарки»; В. Берестов. «Дракон»; Л. Фадеева. «Зеркало в витрине»; И. Токмакова. «Мне грустно»; Д. Хармс. «Веселый старичок», «Иван Торопышкин»; М. Валек. «Мудрецы», пер. со словац. Р. Сефа.<br>***Проза.*** Д. Мамин-Сибиряк. «Медведко»; А. Раскин. «Как папа бросил мяч под автомобиль», «Как папа укрощал собачку»; М. Пришвин. «Курица на столбах»; Ю. Коваль. «Выстрел».<br>***Литературные сказки***. А. Усачев. «Про умную собачку Соню» (главы); Б. Поттер. «Сказка про ДжемаймуНырнивлужу», пер. с англ. И. Токмаковой; М. Эме. «Краски», пер. с франц. И. Кузнецовой. |

**Нәфис-нәфасәти үсеш белем бирү өлкәсе**

**Продуктив эшчәнлекне үстерү.**

**Рәсем**

***Предметлы рәсем.***Рәсемдә предметлар, чынбарлык күренешләре һәм әдәби әсәр образларын чагылдыра белү күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү. Балаларның игътибарын предметларның формасы, зурлыгы, кисәкләренең пропорциясе аерымлыкларына юнәлтү, бу аерымлыкларны рәсемдә күрсәтергә омтылыш уяту.

Предметларның пространстводагы торышын кәгазь битендә күрсәтергә өйрәтү, балаларның игътибарын предметларның яссылыкта төрлечә урнашу мөмкинлегенә (басып, ятып тора; торышын үзгәртә: тереклек ияләре йөгерә, сикерә алалар; агачлар җилле көндә бөгелә-сыгылалар һ.б.) юнәлтү, фигураларның хәрәкәтен чагылдырырга өйрәтү.

Композиция күнекмәләрен үзләштерүгә булышлык итү: предметны кәгазь битендә пропорцияләрен исәпкә алып урнаш тырырга өйрәтү (әгәр предметның биеклеге зуррак булса, аны кәгазь битендә вертикаль урнаштыру, әгәр ул киңлеккә сузылган икән, мәсәлән, бик биек булмаган, ләкин озын йорт икән, аны горизонталь итеп урнаштыру).

Төрле сурәтләү материаллары белән (төсле карандашлар, гуашь, акварель, төсле акбурлар, пастель, сангина, күмер карандаш, фломастерлар, төрле пумалалар һ.б.) ясауның алым һәм ысулларын ныгыту.

Предметның контурын, буяганда сурәтне пычрата торган каты, тупас сызыклар калмасын өчен, карандашка җиңелчә генә басым ясау күнекмәләре булдыру.

Акварель белән, аның үзенчәлекләрен истә тотып (төснең үтә күренмәлелеге һәм йомшаклыгы, бер төснең икенчесенә салмак кына күчүе) ясарга өйрәтү.

Пумала белән ясауның төрле ысулларына: киң сызыкларны — пумаланың бөтен өслеге белән, нечкәләрен — пумала очы белән; зур тапларны пумаланы бөтен өслеге белән кәгазьгә куеп (басып), вак тапларны пумала очы белән ясарга өйрәтү.

Инде таныш булган төсләр турында белемнәрен ныгыту, яңа төсләр (шәмәхә) һәм төсмерләр (зәңгәрсу, алсу, сыек яшел, ачык шәмәхә) белән таныштыру, төс тоемлау сәләтен

үстерү. Яңа төс һәм төсмерләр китереп чыгару өчен (гуашь белән ясаганда) буяуларны кушарга һәм, буяуга су кушып, төсне сыеклатырга (акварель белән ясаганда) өйрәтү. Карандаш белән ясаганда, карандашка басым ясауны көйләп, төрле төсмерләр чыгара белү. Карандашның басымын көйләп, балалар төснең өчләп төсмерен китереп чыгара алалар.

***Сюжетлы рәсем.*** Балаларны әйләнә-тирә тормыш темаларына һәм әдәби әсәрләр буенча («Йомры икмәк кем белән очрашты?», «Ике саран аю баласы», «Чыпчык кайда кунак булган?» һ.б.) сюжетлы композицияләр тудырырга өйрәтү. Композиция күнекмәләрен үстерү, сурәтләрне кәгазь битенең аскы өлешендә бер сызыкта, бөтен биттә урнаштырырга өйрәтү.

Сюжеттагы төрле предмет һәм объектларны зурлыклары буенча чагыштырырга өйрәтү (йортлар зур, машиналар кечкенә, агачлар биек һәм тәбәнәк; кешеләр йортлардан кечерәк, әмма болындагы чәчәкләрдән зуррак). Бер-берсен каплый торган предметларны рәсемдә урнаштырырга өйрәтү.

***Декоратив рәсем ясау.*** Халык һөнәрчеләре эшләнмәләре белән таныштыруны дәвам итү, Дымково, Филимоново уенчыгы, аларның бизәкләре турында белемнәрен ныгыту һәм тирәнәйтү; рус халык декоратив бизәкләре мотивы буенча сурәтләр ясарга тәкъдим итү, аларның төсләр рәте һәм композиция элементлары белән таныштыру, төрле элементларны җиренә җиткереп ясауларына ирешү. Городец бизәге, аның төсләр чишелеше, декоратив төсләрне китереп чыгару үзенчәлеге белән таныштыруны дәвам итү. Полхов-Майдан бизәкләре белән таныштыру. Городец һәм Полхов-Майдан бизәкләрен балаларның иҗади эшләрендә кулланууларына ирешү.

Городец, Полхов-Майдан, Гжель бизәкләреннән орнаментлар төзергә өйрәтү: характерлы элементлары (бөреләр, чәчәкләр, яфраклар, үлән, мыекчалар һ.б. чәчәк-үсемлек мотивлары) белән таныштыру, кәгазь битендә һөнәрчеләр эшләнмәләре формасындагы бизәкләр төшерергә өйрәтү (поднос, чынаяк, тоз савыты һ.б.). Декоратив эшчәнлектә иҗади сәләтләрен үстерү өчен, декоратив тукымалар куллану. Балаларга өс, баш һәм аяк киемнәре (кокошник, яулык, свитер һ.б.), көнкүреш әйберләре (сөлге, салфетка, тастымал һ. б.) формасында киселгән кәгазьләр тәкъдим итү. Бизәкләрне билгеле бер ритм белән урнаштырырга өйрәтү. Кәгазь силуэтлар һәм күләмле фигуралар бизәргә тәкъдим итү

***Әвәләү***

Балаларны төрле материаллардан әвәләүнең (балчык, пластилин, үзле масса) үзенчәлекләре белән таныштыруны дәвам итү.

Натурадан карап һәм күзаллап таныш предметларны (яшелчә, җиләк-җимеш, гөмбәләр, савыт-саба, уенчыклар) әвәләп ясау күнекмәләрен үстерү, аларның характерлы үзенчәлекләрен, кисәкләренең пропорцияләре һәм детальләр зурлыгында аерымлыкларны чагылдыра белүләренә ирешү. Савыт-сабаны балчык һәм пластилин кисәгеннән тасма ысул белән әвәләп ясауны ныгыту. Форманың өслеген тигезләргә, предметларны тотрыклы итәргә өйрәтү.

Әвәләгәндә образның мәгънәлелеген чагылдырырга, кеше һәм хайван сыннарын хәрәкәттә әвәләргә, зур булмаган предмет төркемнәрен гади сюжетларга берләштерергә (күмәк композицияләрдә) өйрәтү («Балалар йөрергә чыккан», «Тавык чебиләре белән чүпләнеп йөри» һ.б.).

Күзаллау юлы белән әдәби әсәрләр геройларын әвәләп ясау күнекмәләре формалаштыру (Аю һәм Йомры икмәк, Төлке һәм Куян, Маша һәм Аю һ.б.). Иҗади сәләт һәм инициативаларын үстерү.

Вак детальләр әвәләү күнекмәләре формалаштыру. Стека кулланып, балыкта тәңкәләр ясарга, күзләрен, хайваннарның йонын, кошларның каурыйларын, кеше киемнәрендә бизәк һәм бөрмәләрен билгеләргә өйрәтү.

Әвәләү өчен төрле материаллар белән эш техникасын формалаштыруны дәвам итү; өстәмә материал куллану теләге уяту (җиләк-җимеш төшләре, ярма һәм мәрҗән бөртекләре).

Пөхтә итеп әвәләү күнекмәләрен ныгыту (балчык һәм пластилин кисәкләрен төшермәскә, киемне пычратмаска, эш беткәч, кулларны юарга).

***Декоратив әвәләү.*** Балаларны декоратив әвәләү үзенчәлекләре белән таныштыруны дәвам итү. Халык декоратив-гамәли эшләнмәләренә кызыксыну һәм нәфасәти караш формалаштыру.

Халык уенчыгы тибында кешеләр, кошлар, хайваннар, әвәләргә өйрәтү (Дымково, Филимоново, Каргопольск уенчыклары).

Декоратив сәнгать предметларына бизәк төшерү күнекмәләре формалаштыру. Әйберләрне гуашь белән буярга, өстенә ябыштыру һәм батынкы рельеф белән бизәргә өйрәтү.

Предметның образын чагылдырырга кирәк булганда, әвәләп ясалган сурәтнең кытыршылыкларын бетерү өчен, кулларны суга манчып эшләргә өйрәтү.

***Кисеп ябыштыру***

Сурәтләр барлыкка китерү ( кәгазьне кыска һәм озын тасма итеп кисү; квадратлардан түгәрәкләр, турыпочмаклыктан овал кисү, бер геометрик фигурадан икенчесен китереп чыгару: квадраттан 2—4 өчпочмак, турыпочмаклыктан — тасмалар, квадратлар яки кечкенә турыпочмаклыклар), бу фигуралардан төрле предмет сурәтләре яки декоратив композицияләр барлыкка китерү күнекмәләрен ныгыту.

Берничә тапкыр бөкләнгән кәгазьдән бертөрле фигуралар, икегә бөкләнгән кәгазьдән — симметрияле сурәтләр ( стакан, ваза, чәчәк һ.б.) кисәргә өйрәтү.

Предметлы һәм сюжетлы композицияләр барлыкка китерү, аларны детальләр белән баету теләге уяту.

Материалларга пөхтә һәм сак караш формалаштыру.

***Сәнгать белән танышу***

Әсәрләрне сәнгать төрләре буенча (әдәбият, музыка, сынлы сәнгать, архитектура, балет, театр, цирк, фотография) аерырга, исемнәрен атарга, төркемнәргә берләштерергә өйрәтү.

Балаларны сынлы һәм музыкаль сәнгать жанрлары белән таныштыру; төрле сәнгатьлелек чараларын аера һәм рәсем ясаганда, музыкаль, театральләштерелгән эшчәнлекләрендә кулланырга өйрәтү; сәнгать эшчәнлеге төрләре өчен материалларны белү һәм исемнәрен атау зарурлыгын төшендерү.

Рәсем сәнгате әсәрләре (И. Шишкин, И. Левитан, В. Серов, И. Грабарь, П. Кончаловский һ.б.) һәм рәссамнар картиналарында туган як табигатенең сурәтләнеше белән таныштыру.

Графика (аның сәнгати чаралары) турында күзаллауларын киңәйтү. Балалар китаплары рәссам-иллюстраторларының (Ю. Васнецов, Е. Рачев, Е.Чарушин, И. Билибин һ.б.) иҗатлары белән таныштыру.

Балаларны архитектура белән таныштыруны дәвам итү. Төрле максаттан чыгып төзелгән биналар барлыгы турында (торак йортлар, кибетләр, театрлар, кинотеатрлар һ.б.) белемнәрен ныгыту.

Балаларның игътибарын архитектура корылмаларының охшаш һәм аермалы якларына юнәлтү (форма, пропорцияләре: биеклеге, озынлыгы; бизәлеш ягы — декор һ.б.). Балаларга бина конструкциясенең аның төзелү максатына ( торак йорт, театр, мәктәп һ.б.) бәйлелеген аңлату.

Күзәтүчәнлекләрен үстерү, биналарны игътибар белән карарга, аларның характерлы үзенчәлекләрен, пропорцияләр, конструкцияләр, бизәүче детальләр төрлелеген күрә белергә өйрәтү.

Әдәби әсәрләр, шул исәптән әкиятләр укыганда, балалар игътибарын әкият өйләрен ( теремкәй, бияләй, тавык аяклы йорт һ.б.), әкият сарайларының сурәтләнешенә юнәлтү.

Нәфасәти тойгылар, эмоцияләр, нәфасәти зәвык, кабул итү сәләте, сәнгать белән кызыксыну үстерү. Сәнгати образ һәм сәнгатьлелек чараларының үзара бәйләнешен билгеләү, мөстәкыйль сәнгать эшчәнлеге өчен төп һәм өстәмә материал сайлау.

Балаларның халык сәнгате, фольклор, музыка һәм сәнгати һөнәрләр турында күзаллауларын киңәйтү. Фольклор бәйрәмнәрендә катнашуга теләк уяту.

Сәнгать әсәрләренә сак караш формалаштыру.

***Сурәтләү эшчәнлеге***

Сынлы сәнгать белән кызыксынуларын үстерү өстендә эшләү. Кабул итү органнары эшчәнлеген (күрү, ишетү, ис сизү, тәм тою) үстереп, балаларның сенсорик тәҗрибәсен баету, предмет һәм табигать объектларының төп формалары турында белемнәрен ныгыту.

Нәфасәти кабул итү сәләтләрен үстерү, әйләнә-тирә дөньяның гүзәллеген тоярга өйрәтү. Предмет һәм күренешләрне күзәткәндә, фикерләү операцияләрен (анализ, чагыштыру, охшату, предмет һәм аларның өлешләренең охшашлыгын һәм аермаларын табу, характерлы үзенчәлекләрен, «гомуми» һәм «бердәнбер» төшенчәләрен ачыклау, гомумиләштерү) үстерү.

Сурәтләгәндә предметларның төп билгеләрен (форма, зурлык, төс) генә түгел, бәлки характерлы детальләрен, кисәкләрнең чагыштырмача зурлыкларын, биеклекләрен, бер-берсенә карата урнашу тәртибен күрсәтергә өйрәтү.

Табигать күренешләрен һәм объектларын күзәтү, игътибар белән карап (тыңлап), алардагы үзгәрешләрне күреп алу сәләтен үстерү (мәсәлән, ничек итеп күктә йөзгән болытларның форма һәм төсләре үзгәрүе, чәчәк таҗларының иртән акрынлап ачылуы, кичен ябылуы, кояшта һәм күләгәдә предметларга төшкән яктылыкның үзгәрүе һ.б.).

Сурәтли белү күнекмәләрен камилләштерү, иҗади сәләтләрен формалаштыру.

Форма, төс, пропорцияләр тоемлауларын үстерү, иҗади зәвык тәрбияләү.

Халык декоратив-гамәли сәнгате (Городец, Гжель, Полхов- Майдан һ.б.) белән танышуны дәвам итү, халык уенчыклары турында (матрешкалар, бирюлькалар) күзаллауларын киңәйтү. Милли декоратив-гамәли сәнгать белән таныштыру (региональ үзенчәлекләргә нигезләнеп). Балаларның декоратив иҗатын үстерү (шул исәптән кумәк эшләр). Үз эш урыныңны җыештыру, шөгыль өчен кирәк булган материалларны әзерләү,пөхтә эшләү, материалларны сакчыл, бәрәкәтле файдалану, эш урынын чиста тоту, эш беткәч, аны тәртипкә китерү күнекмәләре формалаштыру.

Балаларда, барлык эшләрне (рәсем, әвәләү, кисеп ябыштыру) караганнан соң, ирешелгән нәтиҗәләр белән шатлану тойгысы уяту.

***Нәфасәти үсеш мохите***

Әйләнә-тирә мохиткә: балалар бакчасы төркеме бүлмәсе, музыка һәм физкультура заллары, медицина кабинеты, сәнгать студиясе һ.б. га кызыксыну формалаштыруны дәвам итү. Балаларның игътибарын төрле бүлмәләрнең бизәлеш үзенчәлекләренә: стеналарның ачык, тыныч төсләр белән буялышы, тәрәзә пәрдәләренең, бүлмә гөлләренең, ачык төстәге уенчыкларның, халык бизәкләре төшкән предметларның матурлыгына юнәлтү. Балаларда төркем бүлмәсен тәртипле һәм чиста тотарга омтылыш уяту, төркем бүлмәсен бизәүгә тарту.

**“Музыка” белем бирү өлкәсе** түбәндәге бурычларны үти:

- балаларның музыкаль-иҗади эшчәнлекләрен үстерү;
- музыкаль сәнгатькә тарту;

***Музыка тыңлау***

Музыкаль әсәрләрнең жанр төрләрен (марш, бию, җыр) аера белергә өйрәтү. Таныш әсәрләрдән өзекләр тыңлап (кереш өлеш, тәмамлау өлеше, музыкаль фраза), музыкаль хәтерләрен камилләштерү. Квинта эчендә авазларның югарылыгын ишетү, төрле музыка уен коралларын яңгырашы буенча аера белү күнекмәләрен камилләштерү (клавишлы — бәрмә һәм кыллы: фортепиано, срипка, виолончель, балалайка).

***Җырлау***

Җырлау күнекмәләрен формалаштыру, беренче октава «ре»— икенче октава «до» диапазонында җиңел яңгырашлы итеп җырлый белү; җырлар алдыннан, музыкаль фразалар арасында тын алырга, сүзләрне ачык әйтергә, җырны бердәм башлап, бердәм тәмамларга, характерына туры китереп эмоциональ, тасвирлы итеп табигый яңгыравыклы тавыш (уртача һәм тын гына) белән җырларга өйрәтү. Җырларны музыка уен коралына кушылып яисә музыка уен коралыннан башка мөстәкыйль рәвештә ялгыз башкара алу сәләтен үстерү. Төрле характерлы җырларны иҗади башкара алырга һәм башкарганда мөстәкыйльлек күрсәтергә өйрәтү. Яраткан җырларыннан җыр фонды оештыру һәм җыр белән кызыксынуларын, җырлау теләкләрен үстерү.

***Җыр иҗаты***

Бирелгән текстка көй иҗат итәргә өйрәтү. Төрле характерда булган көйләр (бишек җыры, дәртле һәм күтәренке марш, бию көйләре) язу сәләтен формалаштыру һәм үстерү.

***Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр***

Ритмны тою сәләтен үстерү. Музыканың характерын, эмоциональ эчтәлеген хәрәкәтләр аша күрсәтә белү: тирә- юньдә ирекле ориентлашу, гади тезелүләр ясау, музыкаль фразаларга туры китереп кирәк урында мөстәкыйль рәвештә темпны үзгәртү, ягъни уртача темптан, кызу темпка яисә салмак темпка күчү. Бию хәрәкәтләрен башкара алу күнекмәләрен формалаштыру: сикереп, аякларны бер-бер артлы алга сузу, әйләнү, аякларны берсе артыннан берсен ияртеп, чүгәләп алу һәм алга бару, чүгеп, аякларны алга кую. Бию иҗатын формалаштыру.

Жырны сәхнәләштерү күнекмәләрен үстерүне дәвам итү; экиятләрдәге һәм уеннардагы образларның (ат, кәҗә, төлке, аю, куян, карга һ.б.) хәрәкәтләрен төрле уен шартларында мөстәкыйль рәвештә күрсәтә белергә өйрәтү. Рус халык биюләре, түгәрәк уеннары, шулай ук башка халыкларның биюләре белән таныштыру.

***Биюле уен иҗатын үстерү***

Бию иҗатын үстерү; мөстәкыйльлек күрсәтеп, биюләргә үзенчәлекле хәрәкәтләр уйлап табарга, бию композициясен төзергә өйрәтү. Төрле персонажларның хәрәкәтләрен музыкага туры китереп импровизацияләргә өйрәтү; мөстәкыйль рәвештә җырның эчтәлеген чагылдырган хәрәкәтләр, гади генә бию хәрәкәтләре уйлап табарга өйрәтү.

Җырларны, җырлы уеннарны сәхнәләштерүгә кызыксыну уяту.

Музыка уен коралларында уйнау

Гади көйләрне музыка уен коралларында уйнарга өйрәтү; берәрләп һәм зур булмаган төркемнәргә бүленеп, динамикасын һәм темпын саклап, таныш булган гади көйләрне уйнау. Балаларның иҗади сәләтләрен үстерү, мөстәкыйль эшчәнлекләрен активлаштыру.

**Нәфасәти үсеш өлкәсе**

***Сынлы сәнгать юнәлеше. Рәсем***

| А й | № | Тема | Максат |
|---|---|---|---|
| СЕНТЯБРЬ | 1. | Рәсем ясау: «Җәй». | • Образларны аңлап кабул итү, күзаллау сәләтен үстерү. Балаларны җәй көне күргәннәрен искә төшереп, рәсемдә чагылдырырга өйрәтү.<br>• Композиция төзү, кәгазь битен тутырып рәсем ясау, рәсемне кәгазь битенең аскы өлешендә ясау күнекмәләрен үстерү.<br>•Җәйге ял турында сокланып искә алулары аша балаларның иҗади активлыкларын үстерү. |
| | 2. | “Квадратта декоратив рәсем ясау” | • Квадрат эсендә декоратив композиция ясау күнекмәләрен ныгыту (чәчәк, яфрак, коршау).• Пумала белән төрле алымнар кулланып, өйрәтү. Балаларда төс тою сәләтен, нәфасәти кабул итүне үстерү. |
| | 3. | «Татар орнаменты». | • Татар халкының этник һәм милли-мәдәни үзенчәлекләрен саклау һәм яклау максатыннан, балаларны декоратив-гамәли сәнгатьнең гүзәл төре - татар чигеше белән таныштыру.<br>• Татар орнаменты элементларын кулланып, сурәтне полосада урнаштырырга өйрәтү.<br>• Нәфасәти аңлау-кабул итү, композиция төзү күнекмәләрен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 4. | “ Милли кием кигән курчак” | • Татар халкының этник һәм милли-мәдәни үзенчәлекләрен саклау һәм яклау максатыннан, балаларны декоратив-гамәли сәнгатьнең гүзәл төре - татар чигеше белән таныштыру.<br>• Татар орнаменты элементларын кулланып, сурәтне полосада урнаштырырга өйрәтү.<br>• Нәфасәти аңлау-кабул итү, композиция төзү күнекмәләрен ше рәсемен, башын, гәүдәсен , пропорциясен ясарга өйрәнү. Татар орнаменты элементларын кулланып, сурәтне киемдә |
| | 5. | « Көнбагышлар». | • Сары таҗ яфракчыкларының төрле төсмерләрен, орлыклар белән тулы үзәгенең көрән, кара, соры төсләрен рәсемдә күрсәт-кәндә, балаларда төс тою сәләтен, нәфасәти кабул итүне үстерү.<br>• Көнбагышка хас үзенчәлекле билгеләрне (таҗ яфракчыкларының, сабак яфраклары һәм үзәгенең формалары, төсләре) пумала һәм мамык таякчык белән сылап-сылап ясарга өйрәтү. |
| | 6. | «Поезд». | • Транспортның төп өлешләре, детальләре формасын, пропорцияләрен, урнашу тәртибен рәсем аша җиткерергә өйрәтү.<br>• Карандашны төрлечә басып, рәсемне пөхтә итеп буяу осталыгын үстерү.<br>• Балаларны яңа поезд маршрутлары, туган шәһәрнең |
| | 7. | «Яшелчәләр уңышы». | • Акварельнең сурәтләү мөмкинлекләре белән (үтә күренмәле, бер төс өстенә икенчесен сылаганда, төсе үзгәрә) таныштыру.<br>• Акварель белән эшләү ысулларын (рәсем ясар алдыннан, пумаланы суга манып, һәр буяуга берәр тамчы эшләү алымнарын күрсәтү, рәсем турында тулы итеп сөйләргә |
| | 8. | «Алтын көз». | • Миниатюра жанры белән таныштыру.<br>• Дымлы кәгазь битендә акварель буяулар белән рәсем аша көз төсмерләрен чагылдырырга өйрәтү.<br>• Балаларның сүзлек запасын сыйфат сүз төркеме тасвирлары белән (ачык кызыл, алтын, ялкындай кызыл, алсу, чиядәй |
| | 1. | «Көзге келәм» (яфракларны басып рәсем төшерү). | • Традицион булмаган сурәтләү материалларын (көзге яфраклар) кулланырга өйрәтү.<br>• Көз төсмерләрен (ачык кызыл, алтын, ялкындай кызыл, алсу, чиядәй кызыл һ. б.) рәсем аша җиткерү күнекмәләрен ныгыту.<br>• Табигать күренешләренә игътибар итү, күзәтү, алардагы үзгәрешләрне күрү сәләтен үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ОКТЯБРЬ | 2. | «Минем яраткан уенчыгым». | • Балаларның нәфасәти кабул итү сәләтләрен үстерү. Халык уенчыклары белән кызыксыну уяту.<br>• Гомумиләштерелгән уенчык образын рәсемдә сурәтләү осталыгын камилләштерү.<br>• Үзләренең яраткан уенчыгын күрсәтеп, балаларның иҗатка омтылышын үстерү |
| | 3 | “Соңлап килгән көз” | • Балаларның ел фасыллары (көз) турындагы күзаллауларын баету максатында, рәсем эчтәлеген алдан уйлап куярга өйрәтү.<br>• Балаларның көндәлек тормышта алган белемнәренә таянып, иҗатка омтылышларын арттыру. • Балаларның |
| | 4. | “Бүлмә гөле” | • Натурадан кара, тирә-юнебездәге гүзәллекне күрә белергә өйрәтеп,балаларның нәфасәти хисләрен үстерү. • Композиция ясау күнекмәләрен форма-лаштыруны дәвам итү.<br>• Балаларны туган якның тәүге чәчәкләре белән таныштыру. |
| | 5 | “Миләш агачы” | • Миләш яфракларының үзенчәлекле якларын рәсемдә тасвирлау; • Традицион булмаган ысул белән рәсем ясарга өйрәтү.• Балаларны туган якның миләш агачы белән |
| | 6. | “Ирекле темага рәсем ясау” | • Баланың уйлаган хисләрен, уйларын рәсемдә чагылдырырга өйрәтү<br>• Композиция ясау күнекмәләрен форма-лаштыруны дәвам итү.<br>• Фантазияләрен, хыялларын, эстетик тәрбияләрен, |
| | 7. | «Безнең шәһәр урамы». | • Кичке шәһәр йортларын рәсем аша тасвирларга өйрәнү.<br>• Балаларны вазифаларына бәйле булган корылма үзенчәлекләрен рәсем аша күрсәтергә өйрәтүне дәвам итү. |
| | 8. | «Без бәйрәмгә чәчәкләр һәм әләмнәр барабыз». | • Бәйрәмнән алган күтәренке тойгыларны күрсәтә белү. Хәрәкәтләнүче балалар фигурасын рәсемгә төшерегә өйрәтү. Кеше гәүдәсенең өлешләрен бирә алу күнекмәләрен ныгыту. • Акварель буяулар белән ясау, палитрадан файдала-ну күнекмәләрен ныгыту.<br>• Сурәтләнә торган предмет һәм әзер эшләрне чагыштырып, балаларның үзләре һәм башка балалар ясаган рәсемнәргә бәя бирү күнекмәләрен үстерү. |
| | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| НОЯБРЬ | 1. | “Мамин Сибирякның “Соры Муен”әкияте буенча рәсем ясау. | Әдәби әсәргә иллюстрацияләр төзергә өйрәтүдә кызыксыну уяту.<br>Рәсемдә күрсәтергә теләгән эпизодны сайлый белергә өйрәтү.<br>Әкият образларын төзү.Төсле буяулар, карандашлар белән буяу алымнарын ныгыту. Үзеңнең ясаган рәсемеңә кызыксыну уяту, алар турында сөйли белүләренә ирешү. |
| | 2. | “Без балалар бакчасында ничек уйныйбыз” | Кеше фигурасы ясарга өйрәтү, мимика һәм хәрәкәтне дөрес күрсәтеп ясау күнекмәләре бирү. |
| | 3. | “Городец сурәтләре” | • Балаларны Городец бизәкләре һәм аның килеп чыгу тарихы белән таныштыру.<br>• Балаларның композиция ясау күнекмәләрен үстерүне дәвам итү һәм бизәкләрнең таныш элементларын мөстәкыйль |
| | 4. | «Гродец тактачыгы”. | Городецкая роспись белән танышуны дәвам итү. |
| | 5. | Көз белән хушлашу». | • Балаларның ел фасыллары (көз) турындагы күзаллауларын баету максатында, рәсем эчтәлеген алдан уйлап куярга өйрәтү.<br>• Балаларның, шөгыльләр барышында һәм көндәлек тормышта алган белемнәре-нә таянып, иҗатка омтылышларын арттыру. |
| | 6. | “Ирекле темага рәсем ясау”. | • Баланың уйлаган хисләрен, уйларын рәсемдә чагылдырырга өйрәтү<br>• Композиция ясау күнекмәләрен форма-лаштыруны дәвам итү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 7. | “Балалар бакчасында мин нинди уеннар уйнарга яратам” | Кеше фигурасы ясарга өйрәтү, мимика һәм хәрәкәтне дөрес күрсәтеп ясау күнекмәләре бирү. |
| | 8. | “Без балалар бакчасында ничек уйныйбыз” | Кеше фигурасы ясарга өйрәтү, мимика һәм хәрәкәтне дөрес күрсәтеп ясау күнекмәләре бирү. |
| ДЕКАБРЬ | 1. | “Кош” Дымково уенчыгын бизәү. | • Яңа кызыклы юллар табып, Дымково бизәкләре элементларын бергә кушарга өйрәтү.<br>• Балаларның Дымково уенчыклары, би-зәкләре, Дымково уенчык хайваннарын бизәү эзлеклелеге турындагы белемнәрен ныгыту.<br>• Россия халыкларының декоратив сәнгате белән |
| | 2. | “Тылсымлы кош” | • Кошларның канат җилпеп очуларын киң буялыш аша җиткерә белергә өйрәтү.<br>• Кошлар гәүдәсе өлешләренең пропорциональ чагыштырмаларын пумала белән төрлечә буял (пумала очы белән, пумаланы җәеп), рәсем аша җиткерә алу күнекмәсен ныгыту |
| | 3. | «Кышкы урман» (гадәти булмаган эш алымнары). | • Балаларның иҗади фантазияләрен үстерү өчен, аларны төрле предметлар (гадәти булмаган эш алымна-ры) ярдәмендә сурәтләү мөмкинлекләре белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Агач һәм куак сурәтләрен таякчыктан өреп ясарга өйрәтү. |
| | 4. | «Суык бизәкләр төшергән». | • Дулкынлы сызыклар, бормалы-сырмалы бөтеркәләр һәм кар бөртекләрен пумала очын җиңел һәм салмак йөртеп рәсем |
| | 5. | Иң яхшы рәсемгә конкурс: «Кыш | • Балаларны бирем шартлары буенча рәсем ясарга өйрәтү.<br>• Әкияти йортлар рәсемен ясаганда, балаларның шәһәр һәм |
| | 6. | «Солтан-патша». | Балаларны әдәби әсәргә иллюстрация ясарга өйрәтү. .А.С.Пушкинның “Солтан-патша” әкиятен укыгач, туган тәэсирләрне рәсемдә күрсәтә белеүгә ирешү. |
| | 6. | «Чыршы ботагы». | • Ылысларны ясаганда, штрихлау төрләреннән файдаланырга өйрәтү. |
| | 7. | «Кышкы пейзаж». | Рәсемдә таныш җырларның , шигырләрнең образларын сурәтләргә өйрәтү. Төсле буяулар белән эшләү алымнарын, |
| | 8. | «Бака-патшабикә» | Балаларны фантастик образлар рәсемен ясарга өйрәтүне дәвам итү, рзсемне төрле деталләр белән тулыландыру |
| | 1. | “Балалар бакчасында Яңа ел бәйрәме” | Алдан уйланган образларны гәүдәләндереп, кеше фигурасы рәсемен ясарга өйрәтүне дәвам итү. Иҗади омтылышларны, фантазияләрн, якыннарны сөендерү теләкләрен үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ГЫЙНВАР | 2. | «Кыш бабай һәм Кар кызы». | • Кыш бабай һәм Кар кызының әкияти образларын рәсем аша җиткерергә өйрәтүне дәвам итү, предметларның зурлыклары буенча аермаларына, өлешләре пропорцияләренә игътибар юнәлтү.<br>• Фигураларның хәрәкәтләрен рәсемдә күрсәтү күнекмәсен ныгыту. |
| | 3. | «Атлар көтүлектә»-декоратив рәсем. | • Балаларны таныш сурәтләр кушып, рәсемнәрне дөрес итеп урнаштырып, өлешләрен, пропорцияләрен саклап композиция төзергә өйрәтү.. |
| | 4. | «Кыш-лаучы кошлар». | • Гади карандаш белән сызгалап рәсем төшерергә, туган ягыбызда кышлаган кошларга (карабүрекләр, песнәкләр, чып-чыклар, саесканнар) хас үзенчәлекле билгеләрне |
| | 5. | “Бәс каплаган агачлар” | • Балаларны атабигатне сурәтләргә, агач рәсеме ясарга өйрәтү. • Карандаш очы белән ясау күнекмәсен үстерү.<br>• Балаларда табигаткә карата мәхәббәт, соклану хисе |
| | 6. | “Салкын төсләр белән ясалган чәчәк бәйләме” | Балаларның салкын төсләр булуын ныгыту. Салкын төсләр кулланып декоратив композиция төзергә өйрәтү. Нәфасәти кабул итүне һәи иҗади сәләтләрне үстерү. |
| | 7. | “Боланнар йөриләр” | Балаларның таныш сурәтләр кушып, рәсемнәрне дөрес итеп урнаштырып, өлешләрен, пропорцияләрен саклап композиция төзергә өйрәтү.. |
| ФЕВРАЛЬ | 1. | “Алтын хохлома” | . • Россия халыкларының мәдәни үзенчәлекләрен саклау максатыннан, бала-ларны декоратив-гамәли сәнгатьнең үсемлек-чәчәк бизәкләре мотивы белән охшаш яңа төре-хохлома бизәкләре белән таныштыру.<br>• Сылап-сылап рәсем тө-шерү (ромашкалар, яфрак-лар), пумала очы белән эшләү (нокталар, дулкын-лы сызык) алымы кулла-нып, балаларны поло-сада бизәк төшерергә өйрәтү. |
| | 2. | “Әкияти сарай” | Әкияти образга хас үзечәлекләр белән тулыландырып, бина төзелешен рәсем аша күрсәтә белергә өйрәтү. Алдан ниятләп куелган эшне ахырына җиткерү зарурлыгын төшендерү. Әзер образга нәфасәти мөнәсәбәт, аны нәфасәти бәяли белү күнекмәләре булдыру. |
| | 3. | “Кыш” | Балаларны кышкы пейзажны зәңгәрсу фонда акбур һәм гуашь ярдәмендә ясарга өйрәтү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 4. | “Конек-горбунок” | Балаларга рәсем ясар өчен үзләренә әкият эпизодларын сайларга өйрәтү, аларны тулырак тасвирларга өйрәтүгә ирешү. Уйлау һәм иҗади сәләтләрен үстерү. |
| | 5. | Хохлома-декоратив рәсем. | Балаларны хохлома бизәкләре һәм аның килеп чыгу тарихы белән таныштыру. Хохлома бизәкләре элементлары кулланып, полосада сурәт ясарга өйрәтү, пумала белән ясауны, мамык таякчыклар белән баскалау ысуллары белән аралаштырып эшләү. |
| | 5. | «Кышкы урман» (тал төшерү, таякчык белән өрү). | • Балаларны рәсем ясауның төрле техникалары (тап төшерү, таякчык белән өрү) белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Балаларның композиция төзү күнекмәләрен ныгыты-рга, сурәтләрне предметларның кайда урнашуларына карап (алда |
| | 6. | “Вазада агач ботаклары” | |
| | 7. | « Куәтле армиябез». | Әдәби әсәрләр буенча балаларны солдатлар, очучылар, диңгезчеләр сурәтен, аларның тормыш һәм хезмәт итүен күрсәтеп рәсем ясарга өйрәтү. |
| | 8. | «Хохлома подносы». | • Хохлома бизәкләре элементлары кулланып, түгәрәк кәгазь битендә сурәт ясарга өйрәтү, пумала белән ясауны (сабаклар, яфраклар, чәчәкләр) мамык таякчыклар белән баскалау (җиләкләр) ысуллары белән аралаштырырга эшләү. |
| МАРТ | 1. | «Әниемә Городец такта-чыгы». | • Агач тактага, формасына туры китереп, Городец бизәге төшерергә өйрәтү.<br>• Балаларның композиция ясау күнекмәләрен үстерүне дәвам итү һәм бизәкләрнең таныш элементларын мөстәкыйль |
| | 2. | «Песиле тал ботагы». | • Песиле тал ботагын натурадан карап ясарга өйрәнү, рәсемдә аның урнашу үзенчәлекләрен күрсәтү, тиешле төсмерләр табу өчен төсләр кушу.<br>• Төрле калынлыктагы пумалаларны куллану күнекмәләрен ныгыту.<br>• Балаларның композиция ясау күнекмәләрен үстерү. |
| | 3. | «Март ишек төбендә». | • Балаларны дымлы кәгазь битендә аква-рель буяулар кулланып рәсем ясау алымы белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Якын һәм ерак пландагы предметларны сурәтләү күнекмәсе формалаштыруны дәвам итү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 4. | «Әнием портреты». | • Балаларны портрет жанры белән таныштыру.<br>• Кеше йөзенә хас билгеләрне (формасы, төсе, күз уемы, чәч рәвеше) рәсем аша күрсәтә белергә өйрәтүне дәвам итү.<br>• Иң кадерле һәм иң якын кеше буларак анага карата мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләү, балаларның аңа игътибарлы, |
| | 5. | “Бармак буйлы малай”әкияте буенча рәсем ясау. | Балаларны әдәби әсәргә рәсем ясарга өйрәтү. Бу әкиятне укыгач, туган тәэсирләрне рәсемдә күрсәтә белүгә ирешү. Төп геройларны аера белү, рәсем ясаганда аларны битнең |
| | 6. | «Тәүге чәчәкләр». | • Рәсем ясаганда төрле сурәтләү материалларын (балавыз, акбурлар, акварель буяулар) куллана белү.<br>• Композиция ясау күнекмәләрен форма-лаштыруны дәвам итү.<br>• Балаларны туган якның тәүге чәчәкләре белән таныштыру. |
| | 7. | «Синең кем буласың килә». | Балаларны рәсемдә олылар хезмәтен чагылдыра белнргә өйрәтү..<br>• Балаларның профессияләр турындагы белемнәрен ныгыту, кеше тормышында хезмәтнең әһәмиятенә төшендерү; төрле профессия вәкилләренә хөрмәт һәм уңай мөнәсәбәт |
| | 8. | «Әкияти гжель». | • Балаларны рус халкының декоратив-гамәли сәнгате үрнәкләренең берсе - балчык савытларга гжель бизәге төшерү белән таныштыруны дәвам итү. |
| АПРЕЛЬ | 1. | «Минем яраткан экият героем». | Балаларны фантастик образлар рәсемен ясарга өйрәтү, рәсемне төрле детальләр белән тулыландыру күнекмәсен булдыру. Акварель белән ясый белүләрен ныгыту. Уйлау һәм иҗади сәләтләрен үстерү. |
| | 2. | «Төзелеш» | • Балаларга, транспортка хас үзенчәлекләрне (төзелгән катлар саны, кран, бульдозер кебек махсус машиналар) рәсемгә төшерергә өйрәтүне дәвам итү. |
| | 3. | «Хуш исле чәчәкләр». | • Натурадан карап, тирә-юнебездәге гүзәллекне (чәчәкле гөл) күрергә һәм рәсемдә шуны күрсәтә белергә өйрәтү.<br>• Ачык һәм караңгы төсмерләрне аера белү, төсләрне сыеклау һәм куерту күнек-мәләрен ныгыту.<br>• Табигать объектларын күзәтү аша әйләнә-тирә дөньяны нәфасәти кабул итәргә өйрәтү. |
| | 4. | “Чынаякта гжель бизәген төшерү” | Гжель бизәкләре кулланып савыт-саба бизәргә өйрәтү. Балаларның халык иҗаты үрнәкләренә кызыксынучанлык уяту.Пумала очы белән эшләү алымын куллануын дәвам итү. |
| | 5. | «Искиткеч матур туган ягым». | • Балаларны сурәтләү сәнгатенең пейзаж жанры һәм аның төрләре белән та-ныштыруны дәвам итү.<br>• Балаларда туган якка карата мәхәббәт тәрбияләү.<br>• Безне чолгап алган дөнья киңлекләре белән кызыксыну тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 6. | «Уйлап чыгарып ясау». | •<br>• Карандашлар белән пөхтә итеп буярга күнектерү.<br>• Үз рәсемең турында сөйләргә өйрәтү. |
| | 7. | “Төрле төсле ил” | Уйлау, фикерләү сәләтен үстерү. Балаларның төс төсмерләрен, төсләрне һәм төс төсмерләрен төрле алымнар белән күрсәтә белүләрен ныгыту. |
| | 8. | «Натюрморт». | • Балаларны сурәтләү сәнгате жанрлары белән (натюрморт) таныштыруны дәвам итү.<br>• Җиләк-жимешләрне бергә туплап сурәтләргә өйрәтү. |
| МАЙ | 1. | «Чәчәк атучы бакча». | • Балаларны башкалабызның архитек-турасы белән таныштыруны дәвам итү, Казан Кремленең тарихи биналарының, һәйкәлләренең рәсемен ясарга өйрәтү.<br>• Биналарга хас үзенчәлекләрне рәсемдә күрсәтә белү күнекмәсен формалаштыру.<br>• Туган шәһәребез, аның гүзәллеге һәм бөеклеге белән |
| | 2. | «Җиңү көне». | • Әлеге тема белән бәйле предметларны сурәтләп, Җиңү көне турындагы үз хис-кичерешләрен мөстәкыйль җиткерә белергә өйрәтү.<br>• Сурәтне бөтен битне тутырып яки киң полосада урнаштыру күнекмәсен ныгыту. |
| | 3. | «Яз». | Язгы матурлыкны күрә белергә өйрәтү. Рәсемдә табигать күренешләрен, яз үзенчәлекләрен күрсәтә белү күнекмәләрен ныгыту. |
| | 4. | «Туган як». | • Бөҗәкләр төзелешен (күкрәк һәм корсак өлешеннән, алты аяк, канатлардан торган гәүдә) рәсемдә күрсәтеп, балаларда күзаллау формалаштыру.<br>• Күмернең сурәтләү мөмкинлекләре (штрихлау, тон бирү) белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Төрле материаллар кулланып иҗади сурәтләү сәләтен үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 5. | «Унике ай». | •Балаларның табигать күренешләрен, кешеләрнең ел әйләнәсендәге хезмәтен, ялын чагылдырган күренешләрне рәсемдә күрсәтә белү күнекмәләрен ныгыту.Теге яки бу айның билгеле үзенчәлекләрен рәсемдә бирә белүләренә ирешү. |
| | 6. | «Сирень». | • Рәсем ясауның гадәти булмаган ысуллары (пенопласт белән баскалап) белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Рәсемдә төрлечә эшләү ысулларын (пумала һәм бөке белән) бергә үреп бирү күнекмәсен формалаштыру.<br>• Бер төсне сыегайтып яки куертып төрле төсмерләрен кулланырга өйрәтү, төс тоемлауны үстерү. |
| | 7. | «Сабантуй ярышлары ». | • Балаларның алдан уйлап эшләүләренә ирешү. Ярышта катнашучыларның җитезлек, тизлек, көчлелек сыйфатларын катлаулы булмаган сюжет төзеп, рәсемдә күрсәтүгә этәрү. Сабантуй күренешләрен нәфасәти кабул итүгә юнәлтү.<br>• Таяну сызыклары буенча хәрәкәтне, позаны рәсемдә күрсәтә белүне ныгыту. |
| | 8. | “Туган ил” | Эчтәлеген мөстәкыйль уйлап, үзлектән рәсемясый белүләрен ныгыту.Рәсем ясау өчен кирәкле материаллар тупларга, композиция төзергә, эшләрен ахырынача җиткерергә өйрәтү. Туган илгә карата мәхәббәт тәрбияләргә. |

**Әвәләү**

| Ай | № | Тема. | Максат. |
|---|---|---|---|
| СЕНТЯБРЬ | 1. | “Кәрзиндә гөмбәләр». | • Гөмбәләргә хас билгеләрне күрергә һәм ясап күрсәтергә өйрәтү (эшләпә читләренең өскә яки аска таба бөгелеше, батынкы яки кабарынкы булуы, нечкә яки юан төбе һ. б.).<br>• Әвәләп ясау күнекмәсен ныгыту.<br>• Балаларда туган як табигате белән кызыксыну хисе |
| | 2. | «Җиләк – җимешләр”. | Балаларны җиләк-җимешләрнең форма үзенчәлекләрен натурадан карап әвәләргә өйрәтү. Әвәләп ясауның инде таныш алымнарын кулланып, предметларга хас |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ОКТЯБРЬ | 1. | «Кыз туп белән уйный». | • Әвәләп ясаганда, кеше образын күз алдына китереп, аны тәэсирле итеп чагылдыра белү сәләтен формалаштыру.<br>• Балаларның балчыкны (пластилинны) ике уч белән әвәләү күнекмәсен ныгыту. |
| | 2. | «Әтәч гаиләсе белән». | Балаларны әтәч, тавык, чеби фигураларын әвәли белүләрен ныгыту. Композициятөзү осталыгын үстерү, предметларның зурлыкларын чамалап ясарга, хәрәкәтләрен, позаларын эшләнмәдә күрсәтә белергә өйрәтү. |
| НОЯБРЬ | 1. | «Дымково барышнясы». | • Балаларны рус халык иҗат үрнәге -Дымково уенчыгы белән таныштыруны дәвам итү. Халык һөнәрчеләре хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.<br><br>• Балаларны халык иҗаты үрнәкләре (Дымково |
| | 2. | «Мин нәрсә әвәли beләм». | Үзлектән уйлап әвәләргә өйрәтү. Әвәләп ясауда кулай алымнарны сайлый белүләрен ныгыту, балаларның иҗадилыкларын үстерү. |
| ДЕКАБРЬ | 1. | «Кош». | • Төрле зурлыктагы предметларны әвәләп ясарга һәм аларны гомуми композициягә берләштерергә өйрәтү.<br>• Ясалачак образ өслеген шомартып, катнаш ысул белән әвәләп ясый белүне ныгыту. |
| | 2. | «Кышкы бабай». | • Балаларны Кыш бабай образын әвәләргә өйрәтү. Әвәләп ясауның таныш алымнарыннан иң уңайларын, |
| ГЫЙНВАР | 1. | «Әтәч». | • Балаларны Дымково әтәчен әвәләп ясарга өйрәтү.<br>• Әвәләп ясауда кулай алымнарны сайлый белүләрен ныгыту, уйланган эшне ахы-рына җиткерүләренә |
| | 2. | "Күмәкләшеп әвәләү: Зоопаркта җәнлекләр». | •Хайваннарның гәүдә формаларын күзаллаганча алдан уйлап әвәләү аша җиткерә белүне, өслекле тигезләү, шомарту алымнарын ныгыту. |
| ФЕВРАЛ | 1. | "Минем яраткан җәнлегем" | Хайван гәүдәсен әвәләп ясый белүне ныгыту.Әвәләп ясауның төрле ысулларын куллану |
| | 2. | "Мин нәрсә әвәли беләм" | Үзлектән уйлап әвәләргә өйрәтү. Әвәләп ясауда кулай алымнарны сайлый белүләрен ныгыту, балаларның иҗадилыкларын үстерү. |
| | 1. | «Конек-Горбунок" | Балаларны экияти колынны әвәләргә өйрәтү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| МАРТ | 2. | “Әниемә чәчәгем” | Әниләр бәйрәменә пластилиннан чәчәк бәйләме ясау. |
| АПРЕЛЬ | 1. | «Минем яраткан әкият героем” | Әвәләп ясауның таныш алымнарын кулланып, әкият геройларының характерлы үзенчәлекләрен чагылдырып әвәләргә өйрәтү. |
| | 2. | «Ракета» . | • Балаларны ел саен билгеләп үтелә торган Космонавтика көне (12 апрель), космонавтлар хезмәте белән таныштыруны дәвам итү, әлеге профессиягә хас үзенчәлекләрне әвәләп ясаганда күрсәтә белергә өйрәтү. |
| МАЙ | 1. | «Ташбака». | • Балаларның җәнлекләрне әвәләп ясау ысулын мөстәкыйль сайлап эшләү күнекмәсен ныгыту.<br>• Җәнлекләр фактурасын сыгылмалы таякчык белән яки өслекләрен тигезләп ясарга өйрәтү. |
| | 2. | «Доктор Айболит һәм аның дуслары». | • Нинди образ булуга карап әвәләп ясау алымын мөстәкыйль сайларга өйрәтү.Балаларның әкият геройлары образларын әвәләү аша җиткерә белүләрен ныгыту.<br>• Җәнлекләрне әкияти образга хас детальләр белән тулыландырып ясарга өйрәтүне дәвам итү |

**Кисеп ябыштыру**

| Ай | № | Тема | Максат |
|---|---|---|---|
| | 1. | «Гөмбәләр, гөмбәчекләр» | • Аскуйманың үзәгенә яки үзәккә якынрак итеп бер оя гөмбәдән композиция төзергә өйрәтү, балалар үзләре күзаллаганча өстәмә детальләр белән бизәү.<br>• Икегә бөкләнгән кәгазь битеннән бердәй ике кисәк кисү алымы белән таныштыру; почмакларны салмак түгәрәкләп кисү алымын ныгыту. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| СЕНТЯБРЬ | 2. | «Көзге келәм». | • Балаларны симметрияле формалар кисүнең яңа ысулы белән таныштыру.<br>• Эшләү барышында төрле материалларны яраштыру (кәгазь һәм табигый материалларны) күнекмәсен ныгыту.<br>• Көзге төсләр гүзәллеген күреп соклану хисен тәрбияләү.<br>• Балаларны Е. Трутневаның «Листопад» шигыре белән таныштыру. |
| ОКТЯБЬ | 1. | «Вазада яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр». | Балаларны симметрияле формалар кисә белүләрен ныгыту(икегә бөкләп).Сурәтне кәгаз битендә матур итеп урнаштырырга, төсмерләрен туры китереп ябыштырырга өйрәтү. |
| | 2. | «Трамвайда куяннар». | • Шәһәр транспортына хас үзенчәлекләрне җиткерә белергә өйрәтү.<br>• Квадрат һәм турыпочмаклык почмакларын түгәрәкләп кисү, тар кәгазь тасмалар кисеп алу күнекмәләрен ныгыту. |
| НОЯБРЬ | 1. | «Аквариумда балыклар». | Балаларны гади предметлар кисәргә өйрәтү. Балык сыннарын кисү өчен кәгаз кисемтәләреникирәкле зурлыкта алдан әзерләргә өйрәтү. |
| | 2. | "Үзлектән кисеп ябыштыру". | Балаларны эш барышында үзләренең эшләренең эчтәлеген уйларга, кирәкле төсле кәгазне сайларга өйрәтү.Таныш кисү алымнарын кулланып, сурәтләрне кәгаз битенә матур итеп урнаштыра белүләренә ирешү. |
| ДЕКАБРЬ | 1. | «Яраткан уенчыгыңны кис һәм ябыштыр». | Таныш булмаган предметларның сурәтләрен кисә һәм ябыштыра, аларның зурлыгын үлчи, кәгаз битенә матур итеп иурнаштыра белүләрен ныгыту.Сурәтләрне төзү өчен кәгазнең төсләрен тәңгәл китереп сайлый белүне тәрбияләү. Уйлау һәм иҗади сәләтләрен иүстерү. |
| | 2. | «Яңа ел открыткасы». | • Күләмле, панорама рәвешендәге сюрпризлы открыткалар әзерләргә өйрәтү.<br>• Симметрияле итеп кисү осталыгын ныгыту.<br>• Яңа ел бәйрәме - уртак шатлыклы чарага әзерлек вакытында һәр баланы катнаштырып, алар да үзләренең |
| ЯНВАРЬ | 1. | «Кар бөртекләре» | • Балаларны, кайчы белән ике-өч хәрәкәт ясап, киң кәгазь тасмалар кисеп алырга өйрәтү.<br>• Кәгазьдән кар бөртекләрен кисү күнекмәсен үстерү.<br>• Балаларның уен аша аралашуына ирешү. |
| | 2. | «Корабль». | • Кораб өлешенең формасына карап, кисүнең төрле алымнарын кулланырга өйрәтүне дәвам итү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | • Кайчы белән салмак кисү техникасын ныгыту.<br>• Сурәтне образлы бәяләүгә этәрү. Б. Заходерның «Если мне подарят лодку» шигыре белән таныштыру. |
| ФЕВРАЛЬ | 1. | Әтиемә бүләгем. | Матур бүләк ясауга кызыксыну уяту,чиста, пөхтә эшләү күнекмәләренүстерү, матурлыкны күрә белү, соклану хисләре тәрбияләү. |
| | 2. | «Кораблар, пароход-лар». | • Кораб өлешенең формасына карап, кисүнең төрле алымнарын кулланырга өйрәтүне дәвам итү.<br>• Кайчы белән салмак кисү техникасын ныгыту.<br>• Сурәтне образлы бәяләүгә этәрү. Б. Заходерның «Если мне подарят лодку» шигыре белән таныштыру. |
| МАРТ | 1. | «Әнигә котлау открыткасы» | • Ике төстәге кәгазь алып, бер төсне икенчесе өстенә куеп, чәчәкләр кисәргә өйрәтү.<br>• Симметрияле кисү алымнарын (туры-почмаклы кәгазь битен урталай бөкләп, битне бөкләү сызыгы буенча тоткан килеш яртылаш кисү) ныгыту.<br>• Балаларның әйләнә-тирә дөньяны Нәфасәт и кабул итүләрен үстерү. |
| | 2. | «Безнең урамда яңа өйләр». | Балаларны катлаулы булмаган композиция төзергә өйрәтү:өстәмә рәсемнәр кулланып, кәгаз битендә өйләрне төрле юнәлештә урнаштыру. Композиция төзү өчен кирәкле төсләрне сайлый белүләрен, кисү һәм ябыштыру алымнарын ныгыту. Иҗадилык, нәфасәти кабул итүне үстерү. |
| АПРЕЛЬ | 1. | «Айга очабыз». | Кәгазне кисү алымнарын кулланып, уң һәм сул яклары тигез булсын өчен, икегә бөкләнгән кәгаздән ракета формасын кисәргә өйрәтү; ракетаның очу юнәлешен күрсәтеп, кәгаз битенә аңлаешлы итеп урнаштыру. Икегә бөкләнгән кәгаздән скафандрдагы кеше гәүдәсен кисәргә өйрәтү. Эчтәлегенә туры китереп сурәтне тулыландыра белү күнекмәләрен ныгыту. Уйлау, фикерләү сәләтен үстерү. |
| | 2. | «Витамин әфлисуннар». | • Үзәге аша берничә кат бөкләнгән бер төстәге кәгазьдән урталай бүленгән әфлисун кисеп алырга өйрәтү.<br>• Төп форма астына шундый төсмерле кәгазь салып |
| МАЙ | 1. | «Вазада чәчәкләр». | • Ачык һәм җете төсләрдәге чәчәкләргә карата соклану хисе уяту. Формалар һәм төсләр ярашуы матурлыгын күрә белергә өйрәтү.<br>• Күләмле композиция төзергә өйрәтү.<br>• Кайчы белән салмак кисеп, симметрия-ле формалар ясарга күнектерү. |
| | 2. | “Үзлектән кисеп ябыштыру”. | Балаларны эш барышында үзләренең эшләренең эчтәлеген уйларга, кирәкле төсле кәгазне сайларга өйрәтү.Таныш кисү алымнарын кулланып, сурәтләрне кәгаз битенә матур итеп урнаштыра белүләренә ирешү. |

**2.3. Якынча комплекслы - тематик план**

“Туган телдә сөйләшәбез” методик ярдәмлеге буенча- 2012 ел

**Балаларның гомуми белем бирү программасын үзләштерүдә планнаштырылган нәтиҗәләр.**

Бала җиде яшькә җитеп программаны яхшы үзләштергән вакытта, түбәндәге интегратив сыйфатларга ия.

**Интегратив сыйфатлар**

**Интегратив сыйфат “Эмоциональ ярдәмчел “**

Якыннарының һәм иптәшләренең, әкият персонажларының, мультфильмнарның һәм нәфис фильмнарның геройларының эмоцияләрен нечкә рәвештә сизә.

Әдәби әсәрләргә карата эмоциональ халәт күрсәтә, әдәби персонажның эшләгән эшенә карата үзенең мөнәсәбәтен белдерә.

Әдәби әсәрләрнең геройларының эшләгән эшләренең төп яшерен сәбәпләрен аңлый.

Сынлы сүзгә карата сизгер, шигъри юлларның ритмын һәм мелодикасын тоя.

Эстетик хисләрне, тойгыларны күрсәтә, сәнгать белән кызыксына.

**Интегратив сыйфат ”Өлкәннәр һәм иптәшләре белән аралашу”**

Уен башланганчы рольләрне бүлә, үз тотышын исәпли, роль буенча уйный.

Уен эшчәнлеген сөйләм белән терки.

Сөйләм аралашу буларак беренче урынга чыга, балаларның мөнәсәбәтләрен озата.

Үзенә таныш вакыйгалар турында тулы җәенке җөмләләр белән сөйли, иптәшләре белән аралаша.

Сүз осталыгы белән шөгыльләнә, синонимнар, антонимнар куллана.

Тәрбияче яки балалар белән төрле вакыйгалар, тойгылар белән бүлешә.

Төрле әңгәмәләрне күәтли, бәхәсле сорауларны уңай хәл итә.

Иптәшләренең фикере,теләге белән исәпләшә.

**Интегратив сыйфат ”Интеллектуаль бурычларны, проблемаларны хәл итәргә сәләтле”**

Үз-үзенә хезмәт күрсәтә белә.

Әйләнә-тирәдә ориентлаша белә, “алда-артта, өстә-аста, уңда-сулда” сүзләренең мәгънәләрен аңлый.

Төрле вакыйгаларның тәртибен әйтеп бирә ала: башта нәрсә булды, соңрак, атнаның көнен билгели.

Мөстәкыйль рәвештә конструкцияли.

Гади схемалар ярдәмендә мәсьәләләр чишә.

Фикер йөртә һәм аңа сәбәпләр, анализлар ярдәмендә аңлатма таба .

Бирелгән темага үзлектән әкият уйлап таба.

Үзен кызыксындырган эш белән үзлектән шөгыльләнә белә.

**Интегратив сыйфат ”Үзе, гаиләсе, җәмгыять, дәүләт, табигать турында гади кузаллаулар.**

Үзенең, исем, фамилиясен, яшен,гаилә әгзаларының исемнәрен белә.

Әти-әнисенең эш урынын белә, алар эшләгән эшнең җәмгыяткә китергән файдасын әйтә.

Гаилә бәйрәмнәрен белә. Өйдә үзенең вазифалары бар.

Үзенең туган шәһәрен белә, исемен атый, аның турында сөйләп бирә ала.

РФның - күпмилләтле дәүләт икәнен белә.

Россия армиясе, илебезне саклаучы солдатлар, БВС турында белә.

**Интегратив эшчәнлек ”Уку эшчәнлеге белән билгеләнгән универсаль алшартлар”**

Өйдә, балалар бакчасында, урамда үз-үзеңне әдәпле тоту кагыйдәләрен белә.

Кечкенә шигырне ятлый ала, хәтердә калдыру бурычын ути.

Күләме зур булмаган әдәби әсәрләрне бәйләнешле, эзлекле сөйли.

Эшчәнлек вакытында хәтерендә гади шартларны тота.

15-20 минут туплана ала.

Эш кушкач җаваплы рәвештә кабул итә.

Өлкәннәрне яхшы гамәлләр белән сөендерә.

**Интегратив сыйфат ”Кызыксынучан, актив”**

Төрле информацион чыганаклар кулана (кино, әдәби әсәрләр, экскурсияләр һ.б.)

Аралашу вакытында алган мәглуматлар белән, шулай ук конструкцияләү, рәсем сәнгате, уеннар белән кызыксына.

Кызыксынучанлык күрсәтә, танып-белү эшчәнлегенә, тәҗрибәләргә, проект эшчәнлегенә белән кызыксына.

**Интегратив сыйфат ”физик үсеш”**

Антропометрик күрсәткечләр нормада(буе, гәүдә авырлыгы)

Яшенә туры килгән төп хәрәкәтләргә ия була.

Хәрәкәт активлыгына ихтыяҗ формалаша, физик активлык вакытында уңай эмоция күрсәтә.

Уеннар-эстафеталарда катнаша.

Физкультура кирәк-яраклары белән буш вакытында куллана белә.

Үзлектән культура-гигиена күнекмәләрен башкара.

Ашаганда, юынганда тәртип кагыйдәләрен белә.

Сәламәтлекнең кыйммәтлеген, чыныгу кагыйдәләрен үтәвен, көнкүрештә гигиена таләпләрен үтәвен кирәклеген белә.

Үз сәламәтлеген кайгырта башлый.

**Интегратив сыйфат “Үз тәртибе белән идарә итә, үз гамәлләрен тормышка ашыра, гадәттәге норма һәм тәртип кагыйдәләрен саклый”**

Балалар белән сөйләшенеп, коллектив рәвештә эшли белә.

Уен вакытында башкалага карата ягымлы мөгәмалә булдыра, сөйләм чараларыдә бәхәсле сорауларны уңай хәл итә.

Кечкенәләрне кайгырта, аларга ярдәм күрсәтә.

Үз гамәлләрен бәяли белә.

Урамда, балалар бакчасында, өйдә әдәпле булу нормаларын ути.

Ягымлы сүзләрне куллана белә.

**Интегратив сыйфат “Кирәкле алымнарны һәм ысулларны үзләштергән”**

Төрле эшчәнлекләрне үзләштерүдә барлык алымнарга һәм ысулларга ия булу

## 2.3. Якынча комплекс - тематик план

| Сентябрь | | | |
|---|---|---|---|
| | Тема | Максат | Йомгаклау чарасы |
| 1 | Исәнме, мәктәп! | Балаларда мәктәп турында уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. Мәктәпкә бару теләген формалаштыру.Укучы, укытучы, дәрес, тәнәфес сүзләре белән таныштыру. | Мәктәпкә экскурсия оештыру |
| 2 | Безнең балалар бакчасы | Балалар бакчасына карата ярату хисләре тәрбияләү. Балаларның игътибарлылыкларын, куелган максатны аңлый белү сәләтен үстерү. Балаларның күзәтүченлекләрен, хәтерен, бәйләнешле сөйләмен үстерү | Балалар бакчасы буйлап сәяхәт,әңгәмәләр оештыру |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | Алтын көз | Балаларда табигатькә һәм үз исәнлегенә сак караш тәрбияләү. Сөйләшү барышында мәкальләр кулланып, балаларның логик фикерләү сәләтен һәм сөйләм телен үстерү.Тере табигать белән тере булмаган таби гать арасындагы бәйләнешләрне аңларга өйрәтүне дәвам итү. | Әңгәмә “ Көзге урманга сәяхәт” Уен-бирем “Гөмбә ләрне кәрзингә җый. Иҗади сәнгать: рәсем «Гөмбәләр». |
| 4 | Яшелчә бакчасы | Күмәк эшләрдә башкалар белән беррәттән катнашу теләге, тирә- юньдәгеләр өчен кирәкле кеше булу, билгеле бер нәтиҗәләр гә ирешү омтылышы тәрбияләү. Диалогик һәм монологик сөйләмне камилләштерү, образлы фикерләү сәләтен үстерү. | Көзге бизәкләр” темасына табигый материаллардан ясалган поделкалар һәм фотосурәт ләр күргәзмәсе . |

| **Октябрь** | | | |
|---|---|---|---|
| | Тема | Максат | Йомгаклау чарасы |
| 1 | Мин дөньяның бер кешесе | Балаларда әхлакый сыйфатлар, әти-әнигә хөрмәт тәрбияләү. Игътибар белән тыңларга, сорауларга туры бөмләләр белән җавап бирергә күнектерү. | Әңгәмә «Мин бәхетле-мин хокуклы» |
| 2 | Мин яратам сине, “Татарстан” | Балаларда туган якка карата ярату хисләре тәрбияләү. Тирә-юнь турындагы белемнәрен киңәйтү исәбенә сүз байлыгын арттыру, активлаштыру, диало<br>гик сөйләмне үстерү. | Шигырь уку Ә. Синегулов “Татар стан җирләре” |
| 3 | Минем ил , минем шәһәр. | Балаларда туган якка карата ярату хислѐре тѐрбиялѐү.Тирѐ-юнь турындагы белемнәрен киңәйтү исәбенә сүз бай- лыгын арттыру, активлаштыру, диалогик сѐйлѐмне үстерү. Балаларның туган ил турындагы күзаллауларын киңәйтү, «кече илгѐ» карата кызыксыну формалаштыру. | “Минем шәһәрем” темасына рәсем ясау |
| 4 | Сәламәт тәндә - сәламәт акыл | Балаларда үз сәламәтлекләренә карата игътибарлылык, сак караш тәрбияләү. Балаларның үз фикерләрен дөрес итеп җиткерә белү күнекмәләрен үстерү, сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш булдыру | А.Алишның. “Куян кызы” әкиятен сәхнәләштерү. Тәҗрибә эшчәнлеге: Тән температура сын, буйны үлчәү С/р уен “Тикшерү үзәге” |

| **Ноябрь** | | | |
|---|---|---|---|
| | Тема | Максат | Йомгаклау чарасы |
| 1 | Дустың үзеңнән яхшы булсын | Дуслар, танышлар белән тату яшәргә, сабыр булырга, һәрвакыт булышырга, | “Минем дустым” хикәя төзү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | ярдәмгә килергә кирәклеге турында төшендерү. Балаларның кызыксынуын, игътибарын, хәтерен үстерү. Авазларны дөрес итеп әйтергә күнектерү, иҗади сәнгатькә кызыксыну тәрбияләү. | |
| 2 | Табигатьтә көз азагы | Көз турында күзаллауларны ныгыту. Тере табигать белән тере булмаган табигать арасындагы бәйләнешләрне аңларга өйрәтүне дәвам итү. | Урман почмагына экскурсия |
| 3 | Кызыл китап | Балаларның табигатьне саклау турында күзаллауларын киңәйтү. “Кызыл китап” турында белешмә бирү. Балаларның кызыксынуын, игътибарын, хәтерен үстерү. Авазларны дөрес итеп әйтергә күнектерү, иҗади сәнгатькә кызыксыну тәрбияләү | Үстерешле уен “Кы зыл китапта бармы? |
| 4 | Әниләр бәйрәме | Балаларның әниләр бәйрәме турында күзаллауларын киңәйтү, сәнгатьле сөй-ләмнәрен үстерү. Сөйләм телен һәрь-яклап камилләштерү. Балаларда иҗади сәнгатькә, музыкага уңай караш тәрбияләү. | “Аулак өй!” бәйрәм киче.<br>“Әниемнең җылы кочагы” темасы астында рәсем күргәзмәсе. |
| 5 | Салкын саф һава, йомшак кар ява | Балаларда кызыусыну уяту, табигатькә сак караш, экологик бәйләнешләрне күрә белә сыйфаты тәрбияләү. | «Салкын кыш җитте» (әнгәмә)<br>«Кар ява» дигән темага рәсем |

| **Декабрь** | | | |
|---|---|---|---|
| | Тема | Максат | Йомгаклау чарасы |
| 1 | Мониторинг | Балаларның программаны үзләштерүлә-рен тикшерү, анализлау, аерым балалар белән шөгыльләнү өчен план төзү. | |
| 2 | Мониторинг | Балаларның программаны үзләштерүлә-рен тикшерү, анализлау, аерым балалар белән шөгыльләнү өчен план төзү. | |
| 3 | Кыш | Кышкы табигатьнең матурлыгына соклана белү сыйфаты тәрбияләү. Балаларның иҗади күзаллауларын, бәйләнешле сөйләмен үстерү | Кыш турында күр-гәзмәгә рәсем ясау |
| 4 | Бусагада Яңа ел | Балаларның Яңа ел бәйрәме турында күз аллауларын киңәйтү, сәнгатьле сөйләм-нәрен үстерү. Сөйләм телен һәрьяклап камилләштерү. Балаларда иҗади сән гатькә, музыкага уңай караш тәрбияләү. | “Яңа ел маҗарала-ры” темасы астында кулдан эшләнгән әй-берләр күргәзмәсе. |

| **Гыйнвар** | | | |
|---|---|---|---|
| | Тема | Максат | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Кышкы күңел ачулар | Балаларда кызыксыну уяту, табигатькә сак караш, экологик бәйләнешләрне күрә белү сыйфаты тәрбияләү. Балаларның кыш, кар үзенчәлекләре турында белемнәрен баету | "Бәйрәмгә килгән кунаклар" темасына әвәләү. |
| 2 | Транспорт” | Балаларда транспорт йөртүче һөнәр ияләренә карата хөрмәт, ихтирам һәм урамда, транспортта үз-үзләрен дөрес тоту сыйфатлары тәрбияләү. | “Без автобуста барабыз”- әңгәмә с/р уен ”Транспорт” рәсем ясау “Автобус” |
| 3 | Кышкы җәнлекләр тормышы | Балаларда хайваннарга карата кызыксыну һәм сакчыл караш тәрбияләү. Мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерү. | Рәсем буенча хикәя төзү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Февраль** | | | |
| | Тема | Максат | Йомгаклау чарасы |
| 1 | Безнең тәрәзә төбен дә | Балаларда бүлмә гөлләренә карата сак караш тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм, фикерләү сәләте үстерү. Кеше тормышында аларның әһәмиятен аңлату Балаларның кызыксынуын, игътибарын, хәтерен үстерү. Авазларны дөрес итеп әйтергә күнектерү, иҗади сәнгатькә кызыксыну тәрбияләү | Балалар һәрберсе үз гөлләрен утырталар. |
| 2 | “Әллә каян күренеп тора, солдатта булган диләр” | Балаларда кыю. Батыр солдат булу теләге уяту; әтиләре, абыйлары белән горурлану хисе тәрбияләү. Ватанны саклаучылар турында күзаллауларын киңәйтү. Төрле төстә, төрле зурлыкта предметлар белән таныштыру, ш, ә, ч, тартыкларын дөрес итеп әйтергә күнектерү, иҗади сәнгатькә кызыксыну тәрбияләү. | “Әтиемә бүләгем” темасына открыткалар ясау “Әтием белән горурланам”темасы ас тында рәсемнәр күр гәзмәсе |
| 3 | “Сөйдергән дә - тел, көйдергән дә – тел” | Балаларда туган телебезне ярату, зурлау, аңа соклану хисләре тәрбияләү. Халык авыз иҗаты аша балаларның сөйләмен кызыксынучанлыкларын, игътибарларын, хәтерләрен үстерү. Авазларны дөрес итеп әйтергә күнектерү, иҗади сәнгатькә кызыксыну тәрбияләү | Туган тел бәйрәменә шигырьләр өйрәнү |
| 4 | Әниләр бәйрәме | Балаларның әниләр бәйрәме турында күзаллауларын киңәйтү, сәнгатьле сөйләмнәрен үстерү. Сөйләм телен һәрьяклап камилләштерү. Балаларда иҗади сәнгатькә, музыкага уңай караш тәрбияләү. | Әниләргә бүләкләр ясау |

| Март | | | |
|---|---|---|---|
| | Тема | Максат | Йомгаклау чарасы |
| 1 | Әнием бәйрәме | Балаларның әниләр бәйрәме турында күзаллауларын киңәйтү, сәнгатьле сөйләмнәрен үстерү. Сөйләм телен һәрьяклап камилләштерү. Балаларда иҗади сәнгатькә, музыкага уңай караш тәрбияләү | “Бәйрәм иртәсе” |
| 2 | Без язны яратабыз | Туган ягыбызда була торган язгы табигать күренешләренә соклану хисләре тәр-<br>бияләү. Балаларның күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү. | Әңгәмә “Урманда үзеңне тоту”.<br>Уку: яз көне кошлар турында шигырьләр |
| 3 | Без язны яратабыз | Туган ягыбызда була торган язгы табигать күренешләренә соклану хисләре тәр бияләү. Балаларның күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү. | Иҗади сәнгать: рә сем “Яз көне урман” Әвәләү “Кош оясы” |
| 4 | Идел буе халыклар дуслыгы | Балаларның дуслык турындагы мәгълүматларын тулыландыру. Татарстандагы төрле милләт халыкларының дус, тату һәм тыныч яшәүләрен аңлату | Чуваш халык бизәкләре” (кисеп ябыштыру.) |
| 5 | Театр һәм балалар | Балаларда театр сәнгатенә кызыксыну уя<br>ту. Балаларның иҗади сөйләмен, үз тәҗрибәсеннән чыгып сөйли белә күнекмәлә<br>рен үстерү | “Әкият иленә сәя хәт” (әкиятләр сәхнәләштерү) |

| Апрель | | | |
|---|---|---|---|
| | Тема | Максат | Йомгаклау чарасы |
| 1 | Мониторинг | Балаларның үтелгән материалларны үз ләштерү дәрәҗәсен, авыр үзләштерелгән материалны, аңлап җиткермәү сәбәпләрен билгеләү һәм шуның өстендә алга таба эшләү. | Маниторингны тәмамлап отчет ясау. |
| 2 | Без космоста кунакта | Беренче очучы Ю.Гагарин белән танышу. Кояш системасы, планеталар турында элементар белешмә бирү. Санлы кисемтә турында белемнәрне ныгыту | “Нәрсә ул Кояш сис темасы” үстерешле уен |
| 3 | Тукай атналыгы | Г.Тукай экиятлере, шигырьләре аша бала<br>ларда матур әдәбият белән кызыксыну, аларны укырга теләк тәрбияләү.<br>Балаларның игътибарлылыкларын, хетерләрен, фикерләү сәләтен үстерү.<br>Таныш әдәби сюжетлар буенча балалар ның Г.Тукай иҗаты буенча алган белем нәрен камилләштерү. | “Габдулла Тукай татар халкының бәек шагыйре “ темасы астында күргәзмә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 | Язын үсемлекләр һәм хайваннар тор мышы | Язгы табигатьтәге үзгәрешләрне күрә белү һәм яз килүгә сөенү хисләре тәрбияләү. Балаларда яз турында белемнәрен мөстәкыйль эшчәнлектә иҗади куллана белү күнекмәләрен үстерү. Табигатькә карата сак караш тәрбияләү.Ситуатив сораулар ярдәмендә балаларның логик фикерләү сәләтен үстерү.Табигатьтәге бәйләнешләрне аңлата белү күнекмәләрен камилләштерү. | Картина буенча хикәя төзү. |

| Май | | | |
|---|---|---|---|
| | Тема | Максат | Йомгаклау чарасы |
| 1 | Җиңү алып килде яз | Балаларда патриотик хисләр, туган якка, туган телгә, Ватанга мәхәббәт тәрбия-<br>ләү. Туган ил һәм дөньядагы вакыйгалар белән кызыксынучанлыкны үстерү | Котлау открыткасы ясау<br>“Минем бабаем (дәү әтием)-Бөек Ватан сугышында катнаш кан” тарихи кульязмалар, истәлекләр җыю<br>“Җиңү бәйрәме” кичә үткәрү |
| 2 | Минем гаиләм | Балаларда гаилә әгъзаларына хөрмәт, ярату хисләре тәрбияләү. Образлы фикерләү сәләтен үстерү. Балаларның үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзүләренә ирешү | Асфальтта балалар рәсемнәре күргәзмәсе |
| 3 | Исәнме, җәй | Җәйге табигатьнең матурлыгына сокла на белү, күзәтүчәнлек һәм кызыксыну хисе тәрбияләү. Балаларның сүзлек запа<br>сын арттыру, бәйләнешле сөйләм телен, фикерне бер юнәлештә туплый белү сәләтен үстерү. Әкиятләргә кызыксыну уяту, сөйли белү теләге тудыру, аңларга өйрәтү. | Уен-викторина “Чәчәкләр –тормыш яме”. |
| 4 | Исәнме җәй | Җәйге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзәтүчәнлек һәм кызык сыну хисе тәрбияләү. Балаларның сүзлек запасын арттыру, бәйләнешле сөйләм телен, фикерне бер юнәлештә туплый белү сәләтен үстерү. | Рәсем ясау “Ямьле җәй» |

## 2.4 Ата – аналар белән үз ара бәйләнешле эш

Хәзерге фән һәм практика баланың шәхесен формалаштыруда гаиләнең уникаль роль уйнавын исбат итә. Беренче социальләшү гаиләдә башлана, баланың дөньяга, үзенә, башка кешеләргә карашы, мөнәсәбәте формалаша. Ата-аналарның кайгыртучанлыгы балада аның үз-үзенә ышанычын тудыра, башка кешеләр белән түземлек, үзара хөрмәт принциплары нигезендә үзара мөнәсәбәткә керергә әзер торырга ярдәм итә.Ата-ананың тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегендә катнашу мөмкинлеге булу бик зур әһәмияткә ия. Хәзерге заман балалар бакчасы ата-аналарга психологик һәм педагогик ярдәм күрсәтүче учреждение буларак та хезмәт итә.

Шул ук вакытта гаилә дә үзара хезмәттәшлек итәр өчен педагогларны өзлексез үсешкә рухландыра. Түбәндәге бурычларны үтәмичә, максатка ирешү мөмкин түгел:
- гаилә белән партнерлык мөнәсәбәте урнаштыру;
- бакчада ата-анага бала тормышында катнашу өчен шартлар тудыру;
- бала тәрбияләүдә ата-аналарга психологик ярдәм күрсәтү;
- гаиләләр белән үзара аралашуда педагогик компетентлыкны өзлексез күтәрү.

### 2.4.1. Гаилә белән үзара бәйләнеш принциплары.

Психологик уңайлык (комфорт) принципы - ата-аналар белән аралашуда җылы атмосфера булдыру, һәр гаиләнең ихтыяҗын, социаль-психологик характеристикасын исәпкәалу. Ата-ана белән үзара ышанулы мөнәсәбәт ул - хөрмәт, диалогка омтылу, игътибарлылык, ихласлылык. Балага һәм аның якыннарына карата тәрбиячәнең игелеклелеге һәм ачыклыгы ата-ана ягыннан уңай кабул ителә. Ата - аналарның бакчада балалары шат булса, алар тәрбиячеләргә сораулар белән мөрәҗәгать итәләр. Ата-аналарның бала өчен балалар бакчасының уңайлы, куркынычсыз, файдалы булуын күрү генә түгел, ә балаларның үсешен күрүләре дә әһәмияткә ия. Тәрбиячәнең баланың яшь үзенчәлеген, психологиясен, үсеш кризисын белүе, ата-ананы тынычлындырып, кирәкле сүзләр таба белүе, алар белән ягымлы мөгаләмәдәге әңгәмәдәшче булуы мөһим.

Эшчәнлек принцибы. Белем һәм тәрбия бирү процессында балалар бакчасы һәм ата-аналар арасындагы бәйләнештигез хокуклы партнерлар сыйфатына корылган. Партнерлык процессы катлаулы стереотипларның җимерелүе һәм үзара аңлашу урнашу,бала тәрбияләүдә бер үк максатны күздә тоту. Педагогның һәм балалар бакчасының позитив имиджы булуы мөһим.

Бербөтенлек принцибы -тәрбия һәм белем бирүдә гаилә һәм җәмгыять институтларының аерылгысыз бербөтен булуына нигезләнгән. Әлеге принцип бала тәрбияләүдә гаилә белән балалар бакчасының эш стратегиясен билгели. Җәмгыяти тәрбиянең нигезе ул - балага социаль таләпләр системасы кую. Ата-аналарның тәрбияви тәэсире булып, балага карата мәхәббәт, аны куркынычсызлык белән тәэмин итү, аны ничек бар шулай кабул итү тора.

Минимакс принцибы - һәр гаиләгә дифференциальякынкилү, ата-аналар белән эчтәлекле, тактлы аралашу. Ата-аналар белән танышкач, педагог һәр гаиләнең үзенчәлеген ачыклый, аларның активлыгын күтәрү өчен планлы рәвештә шартлар тудыра.

Вариативлык принцибы - ата-аналарга тәрбия һәм белем бирү процессына кушылу һәм аралашуның формаларын тәкъдим итү: традицион һәм традицион булмаган, шәхси һәм төркемләп, дистанцион һәм кара-каршы аралашу.

Өзлексезлек принцибы өйдә һәм балалар бакчасында тәрбия бирүнең өзлексез баруын күз алдында тота.

Иҗадилык принцибы - тәрбия һәм белем бирү процессында барысына да иҗадилык күрсәтергә мөмкинлек ачу.

### 2.4.2. Ата-аналар белән үзара бәйләнеш формалары.

Мәгълүмати чаралар - (телдән журнал, реклама буклеты; балаларга тәрбия һәм белем бирү сораулары буенча мәгълүмати белешмә хезмәте; СМИ да чыгышлар; мәгълүмати кәрзиннәр, хатлар; күрсәтмә психо-педагогик пропаганда һ.б.)

Оештыру эшләре- (ата-аналар җыелышы; анкеталар тутыру; җәмгыяти ата- аналар оешмаларын төзү; коференцияләр, ата-аналар белән берлектә педсоветлар; брифинглар һ.б.)

Культура-агарту чаралары - (ата-аналар мәктәбе; консультацияләр; тематик очрашулар; матур әдәбият буенча тематик күргәзмәләр оештыру; тренинглар; семинарлар; әңгәмә; дискуссияләр; ата-аналар кунакханәсе; түгәрәк өстәл һ.б.)

Оештыру-эшчәнлек - (ата-аналар белән берлектә үткәрелгән балаларның үсеш мониторинга, берләштерелгән ата-ана-бала проекты; күргәзмәләр; вернисажлар; мастер-класслар; балалар, педагоглар, ата-аналар иҗаты; гаилә портфолиосы ясау; иҗади эшчәнлек өчен табигый һәм ташландык материаллар җыю; балалар бакчасын ремонтлауда һәм яшелләндерүдә катнашу;

балаларның бакчадагы тормышын сурәтләгән буклет, видеофильмнар әзерләү, журналлар чыгару;бакчада үткәрелгән чаралар турында фотоматериалларны электрон җибәрүдә булышу; үстерешле предметлы тирәлекнең сыйфатын тикшерүдә катнашу һ.б.)

<u>Ата-аналарның педагогик процесста катнашуы</u> - (ата-аналар катнашы белән шөгыльләр; балаларга әкиятләр уку; балалар белән төрле темага әңгәмәләр кору; ата-аналар катнашы белән сәхнәләштерү; саф һавада йөргәндә, экскурсияләргә барган балаларны озату; Ачык ишекләр, Сәламәтлек көнендә, Шәфкатьлелек марафонында катнашу һ.б.)

**2.4.3 Ата-аналар белән эш төрләренең якынча перспектив планы**

| Ай | Үткәрү вакыты | Эш төре |
|---|---|---|
| Сентябрь | 1 атна | Ата-аналар почмагында көз темасына мәгълүмат әзерләү.<br>Индивидуаль әңгәмә “Көндәлек режимны ничек үтәргә?”<br>“Прививка кирәкме? Прививкалар календаре” күчмә папкасы әзерләү. |
| | 2 атна | Мастер-класс “Бармакларны уйнатыйк”<br>“Табигать бүләкләре” конкурсы.<br>“Сезнең балагыз мәктәпкә әзерме?” темасына анкета тутыру. |
| | 3 атна | “Баланың сөйләмен ничек үстерергә?” Логопед киңәшләре.<br>“6-7яшьлек балаларның яшь үзенчәлекләре” темасына ата-аналар җыелышы үткәрү<br>“Ачык ишекләр” көне. |
| | 4 атна | Консультация “Дөрес туклану”. Лэпбук ясау.<br>“Минем җәйге ялым” темасына рәсемнәр күргәзмәсе. |
| Октябрь | 1 атна | “Сез нинди әти-әни?” темасына анкета тутыру.<br>“Тел – саекмас чишмә” темасына консультация |
| | 2 атна | Консультация “Ял көннәрен ничек файдалы итеп уздырырга”.<br>“Көзге уңыш” рәсем күргәзмәсе. |
| | 3 атна | Бәйрәмгә битлекләр, кирәк-яраклар әзерләү.<br>“Алтын көз” бәйрәме.<br>“Көзге бизәкләр” темасына табигый материаллардан ясалган поделкалар һәм фотосурәтләр күргәзмәсе |
| | 4 атна | Консультация “Сәламәтлекне саклыйк”.<br>Индивидуаль әңгәмә “Гаиләдә хезмәт тәрбиясе” |
| Ноябрь | 1 атна | “Баланың сөйләмен ничек үстерергә? Артикуляцион гимнастика” Логопед киңәшләре.<br>Консультация: “Халык авыз иҗаты әсәрләренең сөйләм телен үстерүдәге әһәмияте” |
| | 2 атна | “Һөнәрләр илендә ” темасына балалар, ата-аналар белән лэпбук ясау.<br>“Грипптан прививкалар ясау кирәкме?”- шәхси әнгәмәләр |
| | 3 атна | “Минем әнием-минем якыным” – әниләр портреты күргәзмәсе.<br>“Уңган куллар”- кул эшләре күргәзмәсе. |
| | 4 атна | “Әнием-кадерлем” бәйрәм кичәсе. |
| Декабрь | 1 атна | Ата-аналар почмагында кыш темасына мәгълүмат әзерләү.<br>Ата-аналар җыелышы ““Гаилә традиияләре һәм балаларга хезмәт тәрбиясе бирү”” |
| | 2 атна | Мәйданчыкны бизәү , балалар өчен кардан тау ясау. |
| | 3 атна | Яңа ел бәйрәменә төркемне бизәү.<br>Котлау газетасы чыгару.Бәйрәмгә әзерләнү.<br>“Яңа ел маҗаралары” темасы астында кулдан эшләнгән әйберләр күргәзмәсе. |
| | 4 атна | “Яңа ел маҗаралары” бәйрәм иртәсе. |

| | | |
|---|---|---|
| Январь | 1 атна | Консультация “Грипп һәм ОРВИ –кисәтү-профилактика чаралары”, “ Кышкы травмалар” |
| | 2 атна | Консультация “Юл йөрү кагыйдәләрен онытма!” |
| | 3 атна | Консультация “Булачак укучының көн тәртибе” |
| | 4 атна | Күчмә папка “Мәктәпкә әзерлек күрсәткечләре” |
| Февраль | 1 атна | Консультация “Кыш айлары файдалы узсын”<br>“Физик тәрбия бирүдә ата-ананың роле” |
| | 2 атна | “Муса Җәлил-безнең йөрәкләрдә” күчмә папка әзерләү.<br>“Минем әтием-солдат” фотогазетасы чыгару. |
| | 3 атна | Әтиләр белән Ватанны саклаучылар көненә багышланган спорт бәйрәме.<br>“Ни өчен балалар рәсем ясыйлар”-шәхси әнгәмәләр<br>“Әтием белән горурланам “ темасы астында рәсемнәр күргәзмәсе |
| | 4 атна | Ата-аналар җыелышы “ Бала сәламәтлеген бергә кайгыртыйк” |
| Март | 1 атна | Ата-аналар почмагында яз темасына мәгълүмат әзерләү.<br>“Алтын куллар” иҗади күргәзмәсе әзерләү.<br>”Әбекәй-алтыным” рәсем күргәзмәсе. |
| | 2 атна | “Әнием-кояшым” бәйрәм иртәсе.<br>Консультация: “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны гаиләдә юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү” |
| | 3 атна | “Нәүрүз” бәйрәме |
| | 4 атна | Индивидуаль әңгәмә «Китап укырга яратасызмы?”<br>“Бала мәктәпкә бара” кушымта әзерләү. |
| Апрель | 1 атна | Консультация: ”Куркынычсызлык.Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру ”<br>Космонавтика көненә иҗади күргәзмә. |
| | 2 атна | “Чит планетага сәяхәт” спорт бәйрәме.<br>“Габдулла Тукай татар халкының бөек шагыйре “ темасы астында күргәзмә |
| | 3 атна | “Ачык ишекләр” көне<br>“Урман бетләреннән сакланыйк!”- күчмә папка әзерләү |
| | 4 атна | “Туган тел бәйрәме”күңел ачу кичәсе .<br>Мәйданчыкны бизәр өчен фигуралар, чәчәкләр, гирляндалар әзерләү . |
| Май | 1 атна | Консультация “Баланы мәктәпкә ничек әзерләргә?” |
| | 2 атна | “Хәрби техника” конкурсы.<br>Җиңү бәйрәме” музыкаль-спорт бәйрәме. |
| | 3 атна | Ата-аналар җыелышы “Сау бул, бакча!”Мәктәп һәм укыту телен сайлау турында әңгәмә.<br>“Сак булыйк! Агулы гөмбәләр”- шәхси әнгәмәләр. |
| | 4 атна | “Бакча белән саубуллашабыз” бәйрәм иртәсе.<br>Җәйге –сәламәтләндерү чорына әзерлек.<br>Консультация “Юлда йөрсәң- бул уяу!” |
| Ел дәвамында | | Балалар бакчасында, шәһәр, республика буенча үткәрелгән балалар өчен конкурсларда, бәйрәмнәрдә, проектларда катнашу. |

### III.Оештыру өлеше.

**3.1. Материаль – техник яктан тәэмин итү**

Барлык эксплуатацияләнүче бүлмәләр Санпин, хезмәт саклау, янгын сүндерү иминлеге, антитеррористик иминлек таләпләренә туры килә.

Төркемдә:

- төркем бүлмәсе,
- йокы бүлмәсе,
- киенү - чишенү бүлмәсе,
- юыну бүлмәсе бар.

Сыйфатлы белем бирүнең шарты булып яхшы материаль - техник база тора.
Белем бирү оешмасында заман таләпләренә туры килә торган материаль – техник база бар: укыту эшчәнлеге өчен кирәкле техник җиһазлар, магнитофоннар, чыгару техникасы.

| № т/с | Җиһазның исеме | Саны |
|---|---|---|
| 1 | Ноутбук | 1 |

**3.2. Программалы – методик яктан тәэмин итү**

***Төп программалар:***

1. Комплекслы программа «Туганнан мәктәпкә кадәр» Веракса Н.Е., Комарова Т.С., Васильева М.А.
2.“Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы”, Р.К.Шаехова, 2012;
3.“Туган телдә сөйләшәбез” 5-7 яшьлек балаларны татар телдә сөйләшергә өйрәтү. Зарипова З.М.

***Парциаль программалар:***

1.Балалар бакчасы: Әти-әниләр һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен уку китабы.- Казан:Раннур, 2003.
2. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти – әниләр өчен хрестоматия. – Казан: РИЦ,2011. – 560 б.
3. Белем һәм тәрбия эшчәнлегенең перспектив программасы «туганнан мәктәпкә кадәр» Н.Е. Веракса, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой..
4. Бондаренко Т.М.Балалар бакчасында физик-сәламәтләндерү эше - Воронеж: ИП Лакоценина Н.А.,2012
